ТЫЕП ТЫЕЛУ

Хәмер сатучы кибетләрнең язмышын төбәкләр үзләре хәл итәчәк

> 6

МЕҢЕ БЕЛӘН КАЙТАРУ

Әҗәткә алып тормыш итүчеләр арткан

> 7

ГҮЗӘЛ ШАКИРОВА:

«Үткәннәргә кайтсам да, барыбер шушы юлны сайлаган булыр идем»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 18 (29178) | Җомга | 9 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАДЕРЛЕ КАДЕРСЕЗЛӘР

ТАТАРСТАНДА ФЕРМЕРЛАР САНЫ КИМИ

Узган ел республикада 128 фермер эшен туктаткан. Нибары 38 кеше генә, тәвәккәлләп, яңа эшен башлап җибәргән. Фермаларын ябып, малларын бетереп, куллары селтәп китеп баручылар арасында ун елдан артык эшләүчеләре дә, дүрт-биш ел гына үзләрен сынап караучылар да бар. Сәбәп нидә? Фермерлар нәрсәдән канәгать түгел? «ВТ» хәбәрчесе аларның үзләре белән сөйләште.

> 5

Ишетми калмагыз

Россия Президентын сайлау бюллетеньнәрендә 4 кандидат күрсәтеләчәк. Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Элла Памфилова белдергәнчә, гамәлдәге дәүләт башлыгы – үзен үзе тәкъдим иткән Владимир Путин, ЛДПР лидеры Леонид Слуцкий, КПРФ әгъзасы Николай Харитонов һәм «Новые люди» партиясе әгъзасы Владислав Даванков рәсми төстә Президентлыкка кандидат булды. Комиссия утырышында Сергей Малинковичны («Коммунисты России») һәм Борис Надеждинны («Гражданская инициатива»), шулай ук үзен үзе тәкъдим иткән Рада Русских һәм Анатолий Баташевны теркәүдән баш тартканнар.
Президент сайлау өч көн дәвамында – 15, 16 һәм 17 мартта үткәреләчәк.

Былтыр төзелгән рейтингларның күбесендә Татарстан алдынгы булган. Бу хакта «ПромРейтинг» агентлыгы китергән тикшерү мәгълүматлары сөйли. Әйтик, республика ЮНЕСКО объектлары саны буенча лидер булган. Моннан тыш, Татарстан төбәккә карата мөнәсәбәт белдерү буенча рейтингта – сигезенче, табигать, климат, экология, тарих, мәдәният, туризм һәм ял буенча уртача бәя исәпкә алынган абруй рейтингында бишенче урынны биләгән.
2023 ел йомгакларына багышланган «РИА Рейтинг» агентлыгы әзерләгән исемлектә республикага дүртенче урын бирелгән. «Авито Недвижимость» тикшерүләренә караганда, Татарстан яңа торак сатып алу һәм көчле килү теләге тудырган төбәкләр исемлегендә алтынчы урында тора.

Быел Ураза бәйрәме – 10 апрельдә, ә Корбан бәйрәме 16 июньдә билгеләп үтеләчәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бу җәһәттән Указ имзалаган. 10 апрель – чәршәмбе. Бу көнне республика законы нигезендә ял итәчәкбез. Корбан бәйрәме исә якшәмбегә туры килә. Димәк, өстәмә ял көне көтелми, чөнки Татарстан бәйрәмнәре ял көненә туры килсә, алдагы көнгә күчерелми.

Яңлларда буран туктаячак. Әмма төнге сәгатьләрдә –27 градуска кадәр суыта.
Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә – 10 февральдә көндез һава температурасы –12...–17 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә температура –16...–21, урыны белән –25 градуска кадәр төшәчәк, аз гына кар явачак. Якшәмбе – 11 февральдә көндез термометрның терекөмеш баганасы –12...–17 градус, иртәнге һәм төнге сәгатьләрдә –19...–24, урыны белән –27 градус күрсәтәчәк.
Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе – 12 февральдә көндез һава температурасының –9...–14 градус тәшкил итүе көтелә. Сишәмбе – 13 февральдә күпчелек районнарда кар явачак.

Районнарда ни хәлләр?

Мамадыш

10 февральдә Мамадышта VIII Бөтенроссия «SUNNYФест» креатив чаналар фестивале узачак. Анда 20дән артык команда катнашыр дип көтелә. Елдагыча, алар шәһәр уртасындагы 3,5 м биеклектәге тауда чыгыш ясаячак, креатив чаналарын тәкъдим итәчәк. Бәйрәмгә килгән кунакларны уха, ботка һәм мичтә пешкән коймак белән сыйларга җыеналар. Лотерея билетлары өләшеп, кыйммәтле бүләкләр дә уйнатылачак. Чара 10.00 сәгатьтән алып 18.00 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк. (vk.com/sunny.fest)

Чаллы

2023 елда Чаллыда 3477 пар кавышкан. Аларның 124е – өлешчә мобилизациягә эләккән ир-егетләр. Бу хакта эшлекле киңәшмәдә ЗАГС идарәсе җитәкчесе Равилә Зарипова хәбәр итте. «Гаилә коручылар арасында өлкән яшьтәгеләр дә бар. Иң өлкән кияүгә – 84 яшь, ә кәләшкә – 78», – диде ул. Соңгы вакытта Чаллыда катнаш никахлар да арткан. Кияүләр арасында Алжир, Бенин, Бразилия, Мисыр, Израиль, Италия, Сүрия, Төркия, Франция, Чили егетләре бар, кәләшләрне Бразилия һәм АКШтан алып кайтканнар. («Шәһри Чаллы»)

Яшел Үзән

Мамадыш-Әкил авылында яшәүче Наилә Ганиева 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Авыл җирлеге башлыгы Фәнис Мирхәтуллин юбилярга Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән Рәхмәт хаты һәм район башлыгы Михаил Афанасьевтан бүләкләр тапшырды. Наилә әби гомере буе колхозда эшли, агач кисә, яшелчә үстерү бригадасында хезмәт куя, җир сукалый. Кыскасы, гомер юлы сикәлтәле дә, катлаулы да була, ә иң мөһиме – хезмәт белән уза. «Чын күңелдән сәламәтлек, бәхет, тыныч тормыш һәм якыннарыгызның хөрмәтен тоеп яшәвегезне телибез», – дип теләде Фәнис Мирхәтуллин. («Яшел Үзән»)

Алабуга

Алабугада Татарстанда беренче махсус хәрби операция музее ачылды. Монда кунаклар игътибарына 50дән артык экспонат тәкъдим ителә. Музей җитәкчесе Роман Епанешников сөйләвенчә, алар арасында хәрбиләргә бирелгән рәсми бүләкләр генә түгел, хәрби хезмәткәрләрнең шәхси әйберләре дә, гуманитар пунктларда эшләнгән окоп шәмнәре, мичләр һәм башкалар бар. «Бөек Ватан сугышына багышланган музейлар, сугыш бетеп, 20 елдан соң гына ачыла башлаган. Ул чакта кайбер документлар югалган булган. Хәзерге вакытта безнең хәрби операциядә катнашучылар белән аралашу мөмкинлеге бар», – диде Роман Епанешников. (tatarstan24.tv)

РОССИЯ ФӘНЕ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның ТӘБРИКЛӘВЕ

Хөрмәтле хезмәттәшләр! Сезне – Татарстанның фәнни җәмәгатьчелек вәкилләрен – Россия фәне көне уңаеннан тәбриклим.

Россия фәннәр академиясе 300 еллык юбилеен билгеләп үтә торган агымдагы елда әлеге бәйрәм аеруча зур әһәмияткә ия. Академия исеменә юлланган күпсанлы котлауларга кушылам һәм аның коллективына Ватаныбыз мәнфәгатьләрендә зур уңышлар телим.

Кеше капиталы, яңа белемнәр һәм технологияләр – социаль-икътисадый алгарышка этәргеч бирүче бәрәкәтле көч. Нәкъ менә шуңа да 2024 ел Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде.

Фәнни хезмәткәрләргә төрлечә дәүләт ярдәме күрсәтү – безнең өстенлекле бурычларыбызның берсе.

Мондый эш күркәм нәтиҗәләр бирә. Татарстанның биш югары уку йорты Стратегик академия лидерлыгы программасында катнаша. Республикада нефть чыгару өлкәсендә дөньяда киң танылган фәнни үзәкләрнең берсе, алдынгы алты инженерлык мәктәбе эшчәнлек алып бара. Күптән түгел Президент Владимир Владимирович Путин катнашуында дөньякүләм дәрәҗәдәге «Югары нефть мәктәбе»нең университет кампусын ачу тантанасы булып узды. Ул дәүләт һәм хосусый эшкуарлык арасындагы нәтиҗәле хезмәттәшлек, зур бизнесның югары социаль җаваплылыгы үрнәге булып тора. Татарстан «Студентлар стартабы» федераль конкурсында җиңүчеләрнең гомуми саны ягыннан Россия төбәкләре арасында алдынгылар сафына, ә Төбәкләрнең фәнни-технологик үсеше илкүләм рейтингында, фәкать Мәскәүдән генә калышып, икенче урынга чыкты.

Республиканың уңышларына, һичшиксез, безнең академик җәмәгатьчелек саллы өлеш кертте.

Технологик бәйсезлеккә ирешү кебек ил өчен гаять мөһим стратегик максатны үтәүгә юнәлтелгән фәнни-техник өлкәдәге сезнең төп казанышларыгыз әле алда дип ышанам.

Сезгә нык сәламәтлек һәм иминлек, һөнәри эшчәнлектә яңа фикерләр, кыю ниятләр һәм башлангычлар, күркәм фәнни нәтиҗәләр телим.

ГАЗ ЮЛЫ

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Газпром» ГАҖ идарәсе рәисе Алексей Миллер белән очрашты.

tatarstan.ru

Санкт-Петербургта Рөстәм Миңнеханов һәм Алексей Миллер газлаштыру эше барышы һәм хезмәттәшлекнең башка юнәлешләре турында фикер алышты. Очрашуда 2025 ел ахырына кадәр Татарстанда газ белән тәэмин итүне үстерү һәм газлаштыру программасын гамәлгә ашыруда Газпром эшенә аерым игътибар иттеләр. Билгеле булганча, 2023 елның декабрендә Газпром Лаеш районында «Юбилейная» автоматлаштырылган газ бүлү станциясен кулланышка тапшырды. Проект нигезендә, гамәлдәге ике станцияне алга таба ябу мөмкинлеге белән ике газүткәргеч яңартылды, шулай ук читкә җибәрә торган газүткәргеч һәм блоклы автоматлаштырылган газ бүлү станциясе төзелде.

Хәзер компания тагын берничә объектны яңарту һәм техник яктан яңадан төзекләндерүгә әзерләнә. Аерым алганда, бу «Дөбъяз», «Тирсә», «Шөгер» газ бүлеп җибәрү челтәрләренә кагыла. Татарстанның Әгерҗе, Азнакай, Әлмәт, Әтнә, Югары Ослан һәм Яшел Үзән районнарында яшәүче газ кулланучыларны, шулай ук Казанның көнбатышында тормышка ашырылачак «Зур Яшел Үзән» проекты территориясен «зәңгәр ягулык» белән тәэмин итү өчен газүткәргеч проектларын төзиләр.

Республиканың газ кергән торак пунктларында да эш туктамый. Бирелдә газлаштырып бетерү программасы (догазификация) тулы куәтенә бара. Исегезгә төшерәбез: «зәңгәр ягулык»ны хуҗалык чикләренә кадәр бушлай китерәләр. Татарстанда яшәүчеләр белән 26,2 мең килешү төзелгән. Аларның 90 проценты буенча эш беткән инде. Медицина һәм мәгариф оешмалары да челтәрле газга күчә. Бүген республиканың Әлки, Алексеевск, Арча, Бөгелмә, Буа, Кама Тамагы, Саба, Сарман һәм Тукай районнарындагы 11 учреждениенең котельные челтәрле газга тоташкан.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

Мортаза Рәхимов Россия дәрәҗәсендәге дәүләт эшлеклесе һәм үрнәк кеше булды.
Бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Уфада Башкортстанның Беренче Президентына һәйкәл ачу тантанасында әйтте. «Чын күңелдән Башкортстанның тугандаш халкына үсеш һәм уңышлар телим», – диде ул.

***

Хөкүмәт йортында узган очрашуда Рөстәм Миңнеханов һәм Федераль юл агентлыгы (Росавтодор) җитәкчесе Роман Новиков юл төзелеше һәм перспективалы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында фикер алыштылар.
2024 елда Әлмәткә кадәр юлны төзеп бетерү планлаштырыла. М7 трассасында Түбән Кама һәм Чаллыны әйләнеп узу юлы төзелә. Шәле – Баулы төбәк автоюлы, Казаннан чыгу юллары төзелә. «Без шулай ук «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты буенча зур эш башкарабыз. «Росавтодор» – барлык юнәлешләр буенча да безнең ышанычлы партнерыбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов. Роман Новиков Рөстәм Миңнехановка, «Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысасында юл хәрәкәте куркынычсызлыгын югары дәрәҗәгә җиткергән өчен, диплом тапшырды. Аны Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин имзалаган.

***

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Азәрбайҗан Президенты сайлавында җиңү яулаган Илһам Алиевка котлау юллады.
«Сайлау йомгаклары илдә яшәүчеләр арасында какшамас абруйга ия булуыгыз, аларның сезнең җитәкчелектә актив төстә хезмәт итәргә һәм стратегик социаль-икътисадый бурычларны хәл итәргә әзер торуларын күрсәтә», – диелә котлауда. Ул Россия белән Азәрбайҗан арасындагы мөнәсәбәтләр кысасында Татарстан һәм Азәрбайҗан арасындагы үзара хезмәттәшлекнең алга таба үсәсенә ышаныч белдергән.

ЯШЬЛӘРГӘ – СҮЗ

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Саратовта Идел буе федераль округы дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнары каршындагы Яшьләр парламентлары ассоциациясе утырышында катнашты.

Утырышта махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүне законнар белән ныгыту, шулай ук гуманитар миссияләрдә катнашуга әзерлек турында сөйләштеләр. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, махсус хәрби операция яшьләрне дә берләштерде. Бер-береңә мөмкин кадәр ярдәм итү теләге, булган кыенлыклар халыкны бердәм итте.

Идел буе федераль округы төбәкләренең закон чыгару җыеннары каршындагы Яшьләр парламенты эшчәнлеге стандарты турында да сөйләштеләр. Ул сайлау, эшчәнлек һәм вәкаләтләрне бер тәртипкә сала. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, яшьләр үзләрен фикер алышуларда, закон чыгару һәм җәмәгать эшләрендә күрсәтә, аннары закон чыгару, башкарма яки муниципаль хакимият органнарында эшләү мөмкинлеге ала. «Аларның активлыгын һәм тәкъдимнәрен күрергә, бәяләргә кирәк», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ассоциация эше кысасында Идел буе закон чыгаручылары берничә социаль объектта булдылар һәм махсус хәрби операциядә яраланган яки авырган кешеләргә ярдәм итү эшчәнлеге белән таныштылар.

2024 гаилә елы

ИЛ ТЕРӘГЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Республикада Гаилә елына багышланган туры эфирлар сериясе башланды. Халыктан килгән сорауларга беренчеләрдән булып Татарстан премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева җавап бирде. Гаилә елы нинди мөмкинлекләр ача? Вице-премьер ярдәм төрләре, федераль һәм республика программалары, Гаилә елына багышланган чаралар турында сөйләде.

Чаралар

Татарстанда Гаилә елы уңаеннан чаралар планын расладылар. Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, ул берничә блокка бүленгән.

– Гаиләгә бәйле иң җитди мәсьәләләрнең берсе – сәламәтлек саклау. Иң күп сораулар да шуның буенча килә. Бу – әниләр һәм сабыйлар, гражданнарыбызның репродуктив сәламәтлеге, – диде вице-премьер.

Ләйлә Фазлыева Гаилә елында районнарда, социаль учреждениеләрдә көн саен диярлек чаралар узачагын әйтте.

– Бу елда гаилә кыйммәтләре турында ешрак сөйләшербез, дип уйлыйм, – диде ул.

Ярдәм

Гадәттә, гаиләләргә социаль ярдәм мәсьәләләре күп сораулар тудыра. Туры эфирда халыктан килгән сорауларның иң күбе төрле түләүләр, пособиеләр, ана капиталы, күпбалалы гаиләләргә ярдәм чараларына бәйле иде. Хәзер алар турында бар мәгълүматны бер урыннан эзләп була. Ләйлә Фазлыева Татарстанда гаиләләргә ярдәм итү чаралары турындагы мәгълүмат тупланган family-tatarstan.ru сайты эшли башлавын әйтте.

– Һәр кеше үзе гаиләсе өчен нинди ярдәм чаралары каралганын, кая мөрәҗәгать итә алганын һәм нинди документлар тапшырып булуын белеп торачак, – дип аңлатты ул.

Ләйлә Фазлыева билгеләп үткәнчә, аз керемле һәм күпбалалы гаиләләргә ярдәм чаралары бүген тулы күләмдә күрсәтелә һәм һәрбер очрак шәхси хәл ителә.

> **Владимир ПУТИН, Россия Президенты:**
> – Гаиләнең төп максаты – балалар тудыру, нәселне, димәк, халкыбызны, күп гасырлык тарихыбызны дәвам иттерү. Гаилә мәдәниятне, милләтне, милли үзенчәлекләрне саклый. Гаилә өйрәтә, тәрбияли, традицияләрне, белемне, шул исәптән һөнәри тәҗрибәне буыннан-буынга тапшыра.

Мәгариф

Ләйлә Фазлыева туры эфир вакытында балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә урыннар белән тәэмин итү мәсьәләләренә аерым тукталды.

– Мәктәпкәчә белем бирүдә урыннар белән тәэмин итү мәсьәләсе һәрвакыт кискен булды. Күпбалалы гаиләләрнең таләпләре үзгәрде. Бүген һәр әти-әни баласының иң яхшы тәрбиячеләр булган яңа балалар бакчасына йөрүен тели, – дип сөйләде ул.

«Демография» һәм «Мәгариф» милли проектлары кысасында соңгы биш елда республикада 50 мәктәп һәм 91 балалар бакчасы төзелгән.

– Әти-әниләр «безгә төземәделәр» дип әйтергә мөмкин. Ләкин саннар үзләре сөйли. Балалар бакчалары төзелә, капиталь ремонт программалары эшли. Быел мәктәпләр дә төзү ниятләнә. Беренче чиратта – мәгариф оешмалары белән хәл иң кискен булган районнарда. Бу – Казан, Усад, Көек, Биектау һәм башкалар. Бу юнәлештә эш бара һәм тукталмаячак, – диде Ләйлә Фазлыева.

Ләйсән САФИНА

Сан

- Татарстанда күпбалалы гаиләләр саны – **50 мең**нән артык.
- Соңгы 5 елда республикада **145 мең**нән артык бала дөньяга килгән.
- Республикада торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә **30 процент** ташламаны **203 мең** кеше алган.
- Җәмәгать транспортында ташламалы йөрү өчен айлык субсидиядән **57 мең** кеше файдаланган.
- 3 яшькә кадәрге балаларга дарулар сатып алу өчен түләүләрне узган елда **49 мең**нән артык кеше алган.

Язучы сүзе

Укымый торган кеше

Әлек укый-яза белгән кеше сирәгрәк булган. Шуңа бу бик зур абруй булып саналган. Чынлап та шулай бит: бары тик күңелендә аң-белемгә омтылышы булган кешеләр генә мондый дәрәҗәгә ирешә алганнар. Хәзерге дөньяда хәреф танымаган кеше юк инде. Ләкин элекке заманның хәреф таныган кешесе белән бүгенге чорның хәреф танучысы бер кимәлдә түгел. Безнең дәвердә хәреф тану әле ул укый-яза икән дигәнне аңлатмый.

Гомумән, бөтенләй бер нәрсә укымый торган, укырга яратмый торган кешеләр була. Кайберәүләр бөтен нәрсәне дә укый, хәтта дару рецепты белән лимонад этикеткасын да, бары тик китап кына укымый. Бу тәрбиягә генә бәйле түгел бугай, бер үк гаиләдә бер үк нәрсә күреп үскән игезәкләр дә ике төрле була ала.

Әдәбиятка мөкиббән киткән бер гүзәлнең дә ярәтып йөргән егете шундыйрак кеше булып чыккан. Әйбәт кеше инде үзе. Бер генә кимчелеге бар. Аңа гына түзеп була бит инде. Ләкин сөйгән кешесенең бер кимчелеген дә калдырмаслык итеп тәрбияләргә тырышмый икән, ул хатын-кыз затыннан була алмый. Кул астындагы барлык мөмкинлекне кулланып бетерә, тик максатына ирешмичә туктамый. Максатына ирешкәч тә туктамый, яңа бер кимчелек уйлап таба да шуны «дәваларга» тотына. Шуңа күрә янында хатын-кыз булу икеләтә рәхәт: күңелле дә, файдалы да.

Сөйгән егетенең китап укый башлавын тели инде бу гүзәл. Үзе Фатих Әмирхан иҗатын бик яраткач, егетенең дә һич югы «Фәтхулла хәзрәт»не укып чыгуын тели. Хәтта укып чыгарга кушып, китабын да биреп җибәрә.

Тәрбиягә шулай тиз генә бирелеп, бер омтылышта камилләшә торган зат булса, ир-ат булмый бит инде ул. Ир-ат ул кәҗә тәкәсе кебек тискәре булырга тиеш, үз җитешсезлекләрен төзәтү турында сүз барганда бигрәк тә. Чөнки бары тик карыша-карыша ризалашканда гына янындагы сөйгәне үз тырышлыгыннан тулы канәгатьлек алачак. Җиңел килгән җиңүнең бәясе булмый.

Егет китапны ачып та карамый инде. Төрле сәбәп табып тик йөри. Аптырагач, кыз шундый шарт куя: «Яки китапны укып чыгасың, яки аерылабыз». Менә монысы инде – авыр мәсьәлә. Берничек тә җиңеп булмый торган. Шундый әйбәт кыздан колак кагасы да килми хәзер, китап укыйсы да килми. Ничек яшәргә дә белгән юк инде бу тормышта.

Тик егет – замана баласы. Барыбер җаен таба. Башта шул китап буенча кино юк микән дип тикшереп карый, шуннан спектакльләргә күчә. Анысы да булмагач, аптырашта кала. Ахыр чиктә, интернеттан әлеге әсәр турындагы язмаларны җыеп, шуларны ятлый. Анда да үзе укымый, кеше тавышы белән укый торган программаларны эшкә җигә. Сөйгән кызы башта бик сөенә инде. Шулкадәр тырышлык салган эшеңнең нәтиҗәсен күрүдән дә зуррак шатлык буламыни! Соңрак шикләнә башлый. Бердән, егете әсәрне укыган һәрбер кеше белергә тиешле нәрсәләрне дә белми, икенчедән, үзенә хас булмаган матур җөмләләр белән сөйли, әдәбият белгече дип торырсың.

Сорый инде шуннан соң. Сорый белеп, нәкъ кирәкле вакытта сорасаң, ир-ат ул сөйгән ярына бөтен серен чишеп ата. Бөтен чынбарлыкны ярып сала, ул гына җитмәсә, азрак су да кушып җибәрергә мөмкин. Кыз упкәләми, кычкырып көлә генә. Китапны укымаса да, әллә нинди катлаулы җөмләләр белән язылган фәнни текстны ятлап утыруын күз алдына китерү барыбер рәхәт бит инде. Көлеп туйгач, өстәп куя:

– Аудиокитап варианты да бар аның, шуны тыңласаң да булыр иде.

– Укымаган адәмнең ул кадәресенә башы җитәмени?! – дип егет тә көләргә тотына.

Болар хәзер берничә ел бергә яшиләр инде. Балалары да бар. «Марат абый, аудиокитапларыгыз юкмы?» – дип язып та җибәргәннәр. Әле менә уйлап утырам... Адәм баласының бердәнбер кимчелеге китап укырга яратмау гына булса, без ничек бәхетле яшәр идек...

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Дуслар эзләгәндә

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне эшкә таксида бардым. Мин күп сөйләшергә яратам бит инде. Машинага кереп утыруга, таксист егеткә күз ташладым. Килеш-кыяфәтен чамалап: «Сез таҗик, ахры», – дидем. «Юк, азәрбайҗан», – ди бу. Урысчасы такы-токы гына, ә мин азәрбайҗанча белмим. Шулай да өч телне, ягъни татарча, урысча, азәрбайҗанчаны бергә кушып, юл буе сөйләшеп бардык тагын.

Аның һәм минем туган телемдә уртак сүзләр булуына сабыйларча шатланган булабыз. Исеме Агил икән, бу, безнеңчә, «акыл» дигән мәгънәдә. «Ә-ә… ызначит акыллы, умный!» – дигән булам, егет елмая. Үзе турында рәхәтләнеп сөйли. Безне мактый. «Сездә яшәргә әйбәт, сездә эш табу да читен, җүнле эш булмагач, акча да юк», – ди. Кыскасы, Татарстанга «шабашка»га килгән Агил. Дөрес, башта бер дусты килеп монда урнашкан, яхшы гына эш табып яши башлаган, аннан, бераз ял алып, Азәрбайҗанга кайткан да Агилны һәм тагын берничә дустын ияртеп килгән.

Кызык инде бу дөнья, безгә әллә кайлардан килеп эшкә урнашалар, канәгать булып яшиләр, ә үзебез эшсезлеккә каршы көрәшәбез. Дөрес, эшлим дигән кешегә эш табыла инде ул, тик безгә ошаганы җитеп бетми.

Улым Булатның әле студент вакытта ук, Америкага барып, акча эшләп кайтуы искә төште әле. Нибары 40 көн тирәсе яшәде ул анда, әмма бер «девятка»лык эшләп кайтты. «Төшемле урын» эзләмәгән, өйләргә мебель ташучы бер фирмага эшкә урнашкан, кичләрен ресторанда савыт-саба юган. Шул ук вакытта Американың үзендә дә «эшсезлек» бар. Улымнан: «Нигә американнар да, синең кебек, шундый эшләргә урнашып, акча эшләмиләр икән?» – дип сораган идем, ул: «Әти, алар мондый эшләрне «кара эш» дип саный, кимсенәләр», – диде.

Әллә без дә дөньяның алга киткән илләре рәтенә бастык микән, дип тә уйлап куйдым. Татарстанга читтән килеп эшләүчеләр ишәйгәннән-ишәя бара. Рәсми мәгълүматлар буенча, узган ел алар 300 меңнән артып киткән. Россия гражданлыгы алганнары 19 мең тирәсе, бу – Казандагылары. Күңелгә төрле уйлар кергәли. Инде исеме онытылган, моннан өч-дүрт ел чамасы элек бер сәясәтче: «Россия тиздән килмешәкләр иленә әйләнәчәк, якындагы 50 ел эчендә 253 миллион мигрант кабул итәчәк», – дигәнрәк сүзләр әйткән иде. Татарстанга шуларның күпмесе эләгер инде.

Бүген бөтен дөньясында бөек күченүләр бара. Бара-бара, кая барып җитәрбез? Бу хәл илнең таркалуына китермәсме, дип тә уйлап куям. Мондый уйлар бик үк нигезсез дә түгел кебек. Дөньяда глобальләшү, бөтендөнья дәүләте төзү шаукымы бара. Ә аның максаты – җирле халыкны бетерү. Дөньяда бер дәүләт, бер халык, бер тел калырга тиешлеге турында сүзләр йөри. Бу сүзләр имеш-мимеш булса гына ярый инде, шулай да куркыта. Бүген бөтен дөньясында ыгы-зыгы, ике система арасында сугыш бара. Һәр як үзенә тарафдарлар, фикердәшләр эзли. Безгә кайсы халыклар теләктәшлек күрсәтер, кем әйтмешли, бер шайтан белә. Шөт, шайтан вәсвәсәсе белән яшәмәбез. Соңгы вакытларда Россиянең ислам дөньясы белән якыная башлавын истә тотсак, тормыш начар булмас. Әнә барлы-юклы ярты сәгать эчендә Азәрбайҗан егете Агил белән тәмам якынаеп беттек бит әле. «ВТ» редакциясе урнашкан бина янына килеп туктагач та, шактый гомер аерылыша алмый тордык. Димәк, рухлар туры килә дигән сүз. Сез ни уйлыйсыздыр инде тагын.

БЕЛЕМСЕЗ АЛДЫРГАН ЧАК

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Үзәк банк гыйнвар ахырында Россия икътисадына үзенең айлык мониторингын игълан итте. Финансчыларның рәсми нәтиҗәсе шундый: күпчелек предприятиеләрдә җитештерү кими башларга мөмкин. Белгечләр әйтүенчә, күп кенә компанияләр бизнес-планнарын паузага куйган, Үзәк банкның төп ставканы төшерүен көтәләр.

Җитештерү кимесә, бәяләр нишли? Югары күтәрелә. Бәяләр югары күтәрелгәндә, Үзәк банк төп ставканы тагын да күтәрергә мәҗбүр була. Ставка күтәрелгәч, бизнес нишли? Җитештерүне киметә. Менә шундый сихерләнгән түгәрәк барлыкка килә. Хәзерге икътисадчыларга һәм финансчыларга бик гаҗәпләнәм мин. Никтер аларның башларында калькуляторлары дөрес эшләми. Банк процентларын күтәреп, инфляцияне һәм девальвацияне туктатып булса, Төркиядә һәм Аргентинада әллә кайчан тотрыклы бәяләр һәм тотрыклы валюта урнашкан булыр иде. Беренчесендә төп ставка – 45 процент, икенчесендә – 133. Лира һәм песо баш әйләндергеч тизлек белән очсызлана, Аргентинада инфляция быел 250 процентка җитәр дип фаразлыйлар. Димәк, төп ставканы күтәрү – төпсез кисмәккә су ташу ул.

Икътисадта бәяләрне күтәрә торган тагын бер мотор бар. Милли валютаның девальвациясе. Импортны алыштыру дип күпме генә шауласак та, аны әлегә параллель импорт белән генә алыштырып була. Сум очсызланганда, товар бәяләре кыйммәтләнми кала алмый шуңа күрә. Әмма бәясе күтәрелгән доллар читкә товар сатучылар кесәсенә акчаны мул коя. Россия нигездә углеводородлар экспортлый, бюджеты да шулардан кергән табыш хисабына тулылана. 2023 ел нәтиҗәләре буенча икътисад хисапларын игълан иткәндә безнең түрәләр фанфаралар кага: бюджет дефициты аяктан екмады, диләр. Шатланырга, чынлап та, урын бар шул: бюджет дефициты ел ахырына 3,2 триллион сумнан артмады. Ә бит май аенда гына еллык дефицит 8 триллион сум булыр, бәлки, 10 триллионга да җитәр әле, дип көткәннәр иде. Дефицит 10 триллионга җитсә, Милли байлык фондында берни дә калмаячак иде. Финанс министрлыгы җәй уртасыннан соң ашыгыч чаралар күрә башлады: сумны очсызландырып, казнага өстәмә табыш койды.

Россиядә «бюджет кагыйдәсе» дигән бер канун яши. Нефть-газ керемнәре билгеле бер суммадан артып китсә, Финанс министрлыгы валюта сатып ала башлый. 7 февральдән ул шул эшкә керешә. Хөкүмәт валюта сатып ала башласа, доллар кыйммәтләнә, ул кыйммәтләнгәч, углеводород керемнәренең сумнардагы күләме дә үсә. Казнага акча ява ягъни. Тагын бер сихерләнгән боҗра пәйда була. Хөкүмәтнең икътисад блогы бик әллә ни кыймылдамыйча гына да бюджет дефицитын киметә, социаль пособиеләр, хезмәт хаклары түләргә казнада акча була. Бу схеманың бер генә кимчелекле ягы бар: инфляция арта, инфляция арткач, янә пособиеләрне үстерергә кирәк була, аларны үстерү өчен тагын сумны девальвациялисең.

Бу боҗралардан чыгу өчен, «җитештерүне арттыру» дигән механизм куллансаң отышлы булыр иде, билгеле. Әмма бу – катлаулы бурыч. Технологияләр кирәк. Технологияләрне дә, җитештерүне дә баш миләреннән һәм квалификацияле эшче куллардан башка үстерү мөмкин түгел. Менә бу соңгы икесе дефицитта. Әйе, әйе, илдә демографик кризис бара. Ләкин эшче куллар дефициты кеше азлыктан түгел. Профессиональ белем бирү системасы аксый. Кирәкле кадрларны тиешле санда әзерли алмый. Әзерләгәннәренең дә сыйфаты түбән. Бу проблеманы берничә фактор тудыра.

Бу юлларның авторы мәктәптән киткәндә, диплом алып китте. Юк, ниндидер уңышка ирешкән өчен бүләк диплом түгел, белем күтәрү курсларында тырышып укып, зачетлар тапшырып алган диплом. Дөресрәге, шулай алынырга тиешле диплом. Болайрак оештырылды ул эш. Яңа стандартлар буенча белем бирү күчкәч, укытучыларның белемен күтәрү тиеш дип табылды. Һәр укытучы онлайн дәресләрдә дә катнашып, лекторларның дәресләренә дә барып белем алырга, биремнәр эшләргә тиеш иде. Моның минем өчен кирәксез нәрсә икәнен әйтеп торуга карамастан, мәктәп администрациясе исемлеккә мине дә тыкты. Болай да ярты ставкага гына йөри идем, өч-дүрт айдан мәктәп белән бөтенләй бәхилләшәсе кеше дәресләргә йөреп мәшәкатьләнмәде, билгеле. Хәер, башка укытучылар да бик әллә ни тырышмады шикелле. Әмма мәктәптән киткәннән соң, кулга бик яхшы катыргыга басылган диплом тапшырдылар шулай да.

Моңа инде күп еллар үтте. Белем күтәрү һәм квалификацияне алыштыру курслары шуннан соң яңарыш кичердеме-юкмы – белмим. Үзәк матбугатта чыккан мәгълүматлар әллә ни зур алгарыш юклыгын күрсәтә. Икътисадның үсеше һәм трансформациясе агентлыгы дигән оешма бар икән. Шул оешма ел саен өстәмә белем бирү кысасында ел саен 7 миллион кеше укый, шуның 10 проценты гына яңа профессия үзләштерә дигән мәгълүмат китерә. Җитмәсә, алары да реаль икътисад өчен кирәкле белем алмый икән. Профессиональ белем бирү йортларын тәмамлаучыларны да, эшкә алгач, яңадан өйрәтергә туры килә.

Өйрәнең сыеклыгы, ягъни кадрларның тиешле квалификациясе булмауның сәбәбе бер: завод-фабрикада эшләп мантый алмыйсың, хезмәт хаклары түбән. Эш бит болайрак тора: квалификациясез һәм белемсез кешеләр тегендә-монда курьер булып йөреп кенә дә, реаль икътисадтагы уртача хезмәт хакыннан берничә тапкыр күбрәк алалар. Шулай булгач, яшьләр станок артына басарга ашкынып тормый инде. Сер түгел: безнең вузлар элек-электән юристлар белән бухгалтерлар әзерләде. Инженер белгечлегенә конкурслар булмады диярлек. Димәк, икътисадны терәү өчен яңадан милли валютаны девальвацияләргә туры киләчәк. Очсызланган сум бюджетка табышны мул бирә. Финанс отчетлары да, сумнарда исәпләнгәч, матур күренә. Халык оттыра да, икътисад оттыра.

Кайчандыр безгә Россиядә 25 миллион югары технологияле эш урыннары булдырырга вәгъдә биргәннәр иде. Эш урыны гына түгел, 25 миллион кадрын табу да хәзер мөмкин түгел.

«Татар-информ»

Зөһрә
САДЫЙКОВА

КАДЕРЛЕ КАДЕРСЕЗЛӘР

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Качу

Узган ел республикада шәхси хуҗалыклар һәм фермерлар 128 млрд сумлык продукция җитештергән, ягъни бу – барлык күләмнең 44 проценты дигән сүз. Бүген фермер хуҗалыкларында 107 мең баш мөгезле эре терлек исәпләнә, аларның 38,6 меңе – сыерлар. Тик Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы китергән мәгълүматлар буенча, узган ел фермер хуҗалыкларында терлекләр 4,5 процентка (5807 баш) кимегән. Әйтик, 2022 ел белән чагыштырганда, маллар Яңа Чишмәдә – 1914, Югары Осланда – 1198, Балык Бистәсендә – 649, Питрәчтә – 610, Арчада 383 башка азайган. Арту нибары ун районда гына күзәтелә. Министр Марат Җәббаров еллык коллегия вакытында моның төп сәбәбен, 5 еллык бурычы беткәч, хуҗалыкларның ябылуына бәйләп аңлатты.

– Әгәр 2022–2023 елларда 710 млн сумлык грант алган 109 хуҗалык уңышлы эшләп китсә, вазгыять яхшы якка үзгәрәчәк. Тагын дүрт эшмәкәр 38 млн сум күләмендәге ярдәмне быел алачак, – диде ул.

Әйе, уңышлы эшләп киткән очракта. Тик аларга моның өчен шартлар тудырыламы? Әйтик, Арча районының Пөшәнгәр авылында яшәүче Илһам Низамов ун елдан артык фермер хуҗалыгы тоткан. Тик быелдан ул КФХны ЛПХга, ягъни шәхси хуҗалык итеп күчергән. Дөрес, 40 баш терлеген дә киметмәгән, җирләрен дә бетермәгән.

– Эш ачканда, гаилә фермеры буларак, 1 млн сум субсидия алган идем. Бер тиен акча юк чакта мондый ярдәм алу яхшы булды. Ул вакытларда ферманы төзеп чыгу 3 млн сумга баса иде. Җитеп бетмәгән акчаны дуслардан, туганнардан җыеп, ферманы аякка бастырдык. Җир документлары да бик вакытлы әзер булды. Кыскасы, эшләргә кызык иде, ә хәзер берминди дә файдасы калмады. Грант, субсидия алу Берлинны алуга тиң. Шуңа күрә фермер булдым ни дә, шәхси хуҗалык булып эшләдем ни, аермасы юк, – диде ул.

Аның сүзләренчә, соңгы елларда фермерлар эшчәнлегенә таләпләр дә катгыйланган.

– Тирес түккән өчен дә документ сорый башлауга калгач, юк инде ул, – дип күрсәнә кичәге фермер.

Кадере артырмы?

Узган ел Азнакай районында җиде фермер эшен туктаткан, дүрт кеше шәхси хуҗалык булып эшли башлаган. Эшләрен туктатучылар арасында өчесе – грант алып, биш еллык бурычын үтәүчеләр.

– Яңа гына грант алып эш башлаучыларны салымнар, тикшерүләр куркыта. Бу – замана таләбе, тик күпләр аны булдырып чыга алмый, – ди районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Рамил Исламов. – Моңа кадәр грантта башлыча өлкәннәр, элек үзләре колхозда эшләгән кешеләр катнашты. Яшьләр әле үзләрен күптән түгел генә программаларда сыный башлады. Теге буйн картайды, эшләрен тапшырыр кеше юк. Моннан тыш, узган елгы сөт бәяләре һәм корылык фермерларга нык сукты.

Аның фикеренчә, авылда фермерларның үз урыны һәм роле бар.

ФЕРМЕРЛАРНЫҢ ЭШЛӘРЕН ТУКТАТУ СӘБӘПЛӘРЕ

- җитештергән продукциянең түбән бәядән сатылуы;
- техника, ягулык, ашламаларның чамадан тыш кыйммәтләнүе;
- кадрлар кытлыгы, фермерларның картаюы, буыннар бәйләнеше өзелү;
- кредит ставкаларының, салымнарның югары булуы;
- төрле тикшерүләр, анализлар.

– Авылда барыбер үз эшен алып баручы бер-ике кеше була. Безнең районда, мәсәлән, өч авылда гына авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче кеше юк. Яхшымы, начармы, алар эшли. Халыкны итле һәм сөтле итәләр, беренче чиратта сыйфатлы продукция җитештерәләр. Көндәшлек өчен дә кирәктер, дип саныйм. Дөрес, алар күп вакыт агрохолдингларга да, шәхси хуҗалыкларга да оттыра, көндәшлеккә сәләтле түгел. Шулай да мин аларның эшчәнлеген бөтенләй бетереп атмас идем. Ирекле авылында Айрат дигән егетебез заманында грант алып эшли башлаган иде. Бүген ул – авылны тотып торучы кеше. Андыйлар тагын бар. Миңа калса, бу авыр чорны узып, киләчәктә фермерларның кадере артыр.

Мәсгут авылында яшәүче Ринат Вафиев узган ел эшен туктаткан. Артта – ун еллык хезмәт, 150 баш терлек. Үзе шаяртып: «Картайдым, күпме эшләргә була инде?» – дисә дә, сәбәпләре тирәндәрәк булып чыкты.

– Соңгы елларда табигать шартлары шактый сынады безне. Ашлыкны сатып алырга туры килде, ә саткан сөтнең бәясе юк. 11 сумга тапшырып, файдасы ничек булсын? Салымнар да туйдырды. Керемен саныйлар, чыкканы исәптә юк. Безнең авылда берничә яшь фермер бар, ләкин аларга бер ярдәм дә юк бит. Грант акчасын барыбер кире алып бетерәләр. Беренчедән, сөтне арзанга алалар, икенчедән, салымын түләттеләр, өченчедән – Пенсия фонды. Бернинди дә ярдәм кирәкми, бары тик салымны гына бетерсеннәр яки киметсеннәр. Аннан соң терлек техника түгел бит, сүндереп куеп булмый. Бер көнгә дә калдыра торган түгел. Әле болай да кечкенә бозауларны бөтенләй сатып бетермәдем. Өйдә дә атасы килми, хәрәкәт булсын дип, шул тананаларны карыйм. Колхозны бетергәндә, 5–6 ферманы үземә алган идем. Аларны ташлап кайтып китсәң, гел юкка чыгарачаклар. Ә тапшырырга башка кеше юк, – диде ул.

Я отасың, я ятасың

Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров әйтүенчә, әлеге вакытта республикада 4 меңнән артык фермер хуҗалыгы теркәлгән.

– Соңгы берничә елда аларның саны кими, узган ел аеруча нык сизелде. Чөнки, беренчедән, сөт һәм ашлык бәяләре бик түбән тәгәрәде. Күпләр, фермерлыктан китеп, шәхси хуҗалык буларак эшләүне отышлырак дип санады. Моннан тыш, дәүләттән алына торган ярдәм дә тигез бүленми. Узган ел шәхси хуҗалыклар һәм фермерлар җитештергән продукция барлык күләмнең 44 процентын алып тора. Ә дәүләттән ярдәмне 16,8 процент кына алганнар. Эре агрохолдингларга исә мондый ярдәмне биш тапкыр күбрәк биргәннәр. Әгәр алынган ярдәм буенча карасак, эре хуҗалыклар продукцияне дә биш тапкыр күбрәк бирергә тиеш бит. Бу турыда күп сөйлибез, тик нәтиҗә юк, – ди ул.

Әлеге фикерне Чүпрәле районының тәҗрибәле фермеры Равил Бикчуров та дәвам иттерде.

– Эре агрохолдингларга ташламалар зур, ә фермерларга аларны ясамыйлар. Элек субсидияне техниканың 40 проценты күләмендә бирәләр иде. Хәзер 30 процентка калдырдылар. Әле аның да акчасын өчәр ел алмаган фермерлар күп. Соңгы елда ярдәмне бөтенләй кистеләр. Әйтик, 10 млн сумлык техника алган очракта, хөкүмәттән 3 млн сумы кире кайтарылырга тиеш. Тик хәзер аны 2 млн сумга гына калдырганнар. Яңа эш башлаган фермер өчен бу – бик нык аяк чалу. Шуңа күрә аларның саны елдан-ел кими, – ди ул.

Исем-фамилиясен газетада күрсәтүне теләмәгән кооператив әгъзасы да, фермерларның күпчелеге төрле басымга түзә алмыйча эшен туктата, дип саный.

– Үзебез ничек тә тырышабыз, тик эшләрен ничарадан бичара туктаткан кешеләрне бик яхшы аңлыйм мин. Кул хезмәтеннән бигрәк, документ эше күп. Һәр төрле анализлар да шактый акча таләп итә. Эш башлаганда, каян булырга тиеш икән ул? Шуңа күрә кешеләр «астан» гына эш алып бара башлый. Грант, программаларда катнашканда бизнес-планнар да пилот проекты кебек кенә эшләнә. Аны тормышка ашыруга нибары җиде ел бирелә. Ул вакыт эчендә я күтәреләсең, я ябыласың. Тиздән эре холдинглар гына калыр, ахрысы. Башкалар кысрыклауга чыдый алмас. Эшлим дигән кешенең дә бугазына басалар, – диде ул.

Район	Эш башлаучылар	Эшләрен туктатучылар	ЛПХга күчүчеләр
Әгерҗе	0	1	6
Азнакай	4	7	4
Аксубай	1	4	2
Арча	1	7	6
Баулы	0	7	0
Биектау	4	1	1
Кама Тамагы	0	6	4
Кукмара	0	13	6
Мөслим	3	10	0
Балык Бистәсе	1	13	2
Сарман	2	9	2
Спас	0	6	0
Чирмешән	0	0	0

Күрсәткечләрне Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тәкъдим итте.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

БЕТМИ ТИК СУСАУ

ru.freepik

Моннан ары күпфатирлы йортларның беренче катында урнашкан хәмер сатучы кибетләрнең язмышын һәр төбәк үзе хәл итәчәк. Узган атнада Дәүләт Думасында әнә шундый эчтәлектәге закон кабул иттеләр. Халык телендә «наливайка» дип аталучы әлеге кибетләрдә кызыктыргыч исемле эчемлекләр дә булырга тиеш түгел. Яр-р-рамый! Ул арада быелтыр Татарстанның 43 районында (!) хәмерне халыкка сату күләме арткан. Тыеп кына тыелып буламы? Мәңгелек булып тоелган сорауга «ВТ» хәбәрчесе җавап эзләде.

Тансык закон

Гомер буе Казанда укытучы булып эшләгән, хәзер лаеклы ялдагы Тәслимә Гарифуллина картлык көнендә тынычлыгы булмаудан зарлана.

– Моннан ике ел элек без яшәгән күпфатирлы йортның беренче катында хәмер сатучы кибет ачылды. Көндез дә, төнлә дә исерекләр йыелып ята. Мөрәҗәгать итмәгән җир калмады. Баксаң, кибеткә керү юлы ишегалдында булмаса, мондый сәүдә рөхсәт ителә икән. Соң ул исерекләр кая китсен? Эчәләр-эчәләр дә ишегалдындагы балалар мәйданчыгында йә булмаса подъезд ишеге төбендәге эскәмиядә кәеф-сафа коруларын дәвам иттерәләр. Икенче катта яшәгәч, тавыш бик нык ишетелә. Бер чеметем йокы күрмәгән төннәрем дә бар, – ди Тәслимә апа.

Яшерен-батырын түгел, күпфатирлы йортларның беренче катында урнашкан аз градуслы хәмер сатучы кибетләргә ияләшеп беттек кебек. Бүген адым саен диярлек «наливайка»лар төрле утлар белән җем-җем яна. Интернеттагы мәгълүматларга ышансаң, Казанда гына да 850гә якын алкоголь сатучы сәүдә ноктасы бар. Чагыштыру өчен, шул ук чыганаклар буенча башкалада даруханәләр саны 1 мең тирәсе.

Ниһаять, халыкның моң-зарын да ишеткәннәр. 1 февральдә Дәүләт Думасында ил төбәкләренә күпфатирлы йортларның беренче катында сыра, сидр кебек алкогольле эчемлекләр сатучы сәүдә нокталарының эшчәнлеген көйләү хокукын бирүче закон кабул иттеләр. Моннан ары аз градуслы алкогольле эчемлекне сату вакытын да чикли алачаклар. Бу мәсьәләне төбәкләр үзләре хәл итә.

Спиртлы эчемлекләрне халыкка сату күрсәткече иң күп арткан һәм кимегән районнар

Арту	Кимү
Лаеш (+15%)	Апас (−4%)
Югары Ослан (+14%)	Арча (−2%)
Питрәч (+12%)	
Биектау (+11%)	
Яңа Чишмә (+10%)	

Татарстанда җитештерелгән аракы иң күп, иң аз сатылган шәһәр һәм районнар

Арту	Кимү
Яңа Чишмә (+7%)	Апас (−8%)
Югары Ослан (+6%)	Казан (−5%)
Лаеш (+5%)	Лениногорск (−5%)
	Чаллы (−4%)
	Арча (−4%)

Исеме дә ярамый

Яңа закон кайчан эшли башлый? Мәсьәләгә ачыклык кертүне сорап, закон проекты авторларының берсе, Дәүләт Думасының Икътисадый сәясәт буенча комитеты җитәкчесе Максим Топилинга мөрәҗәгать иттек.

– Бу – ил төбәкләрен борчыган мәсьәлә. Дәүләт Думасында күпфатирлы йортларның беренче катында урнашкан исерткеч эчемлекләр сатучы кибетләр турында без моңарчы да бик күп фикер алыштык, – дип сөйләде депутат «ВТ» хәбәрчесенә. – Төбәкләр нәрсә ди? Әш шунда ки, гамәлдәге закон нигезендә, төбәкләрнең күпфатирлы йортларның беренче катында урнашкан гомуми туклану урыннарында хәмер сатуны гомумән тыю хокукы бар. Әмма алар бу юлдан барырга теләми. «Әлеге төр бизнес бөтен җирдә дә, һәркемгә дә комачау итми бит», – ди алар. Шуңа күрә әлеге эшчәнлекне көйләү хокукын бирүне сорадылар. Шулай эшләдек тә.

Максим Топилин әйтүенчә, бүген җәмәгать урыннарында тынычлыкны бозган өчен штрафлар бар.

– Шуңа күрә күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең тынычлыгын хокук саклаучылар тәэмин итә. Барлык төбәкләрдә дә моның өчен тиешле көчләр җитешмәве дә аңлашыла, әлбәттә. Фикер алышу барышында һәр якны да канәгатьләндерерлек чишелеш таптык дип уйлыйм. Шул рәвешле дуслары, гаиләсе белән бергә тыныч кына ял итәргә теләүчеләр дә бар бит. Яңалык рестораннарга кагылмый. Бу – ашаучының цивилизацияле формасы. «Наливайка» дигәндә исә көндез, ваклап, алкогольле эчемлекләр сатучы, төнлә исә өстәлләр куеп, эшен дәвам иттерүче кибетләр күзаллана. Мондый эшчәнлек закон нигезендә тыелган. Бер үк мәйданда товарны ваклап сатарга һәм аны гомуми туклану урыны итеп тә файдаланырга ярамый. Ваклап сату икән, димәк, шешә ябык килеш сатыла. Ә гомуми туклану урыны дигәндә: шешә ачык, исерткечне дә шунда ук эчәләр. Әнә шул ике эшчәнлек бер урында алып барыла алмый. Мондый күренешкә тап булсагыз, турыдан-туры күзәтүче органнарга яки полициягә хәбәр итәргә кирәк, – дип ачыклык кертте Дәүләт Думасы депутаты.

Закон бу елның 1 апреленнән үз көченә керәчәк. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин төбәкләрдә әлеге законның үтәлешен контрольгә алырга да кушкан.

Тагын бер яңалык – закон исерткеч эчемлекләргә кешене алдый торган исемнәр бирүне дә тыя.

– Узган ел «Мистер сидр» тирәсендә килеп чыккан хәлләрне генә искә төшерегез. Әлеге эчемлекнең, гомумән, сидр булмавы ачыкланды. Куркыныч исерткеч җитештерүчеләр бөтен технологияләрне бозган. Өстәвенә, эчемлеккә куркыныч агу – метанол өстәгәннәр. Теге яки бу товарның атамасы ялгыш фикер йөртергә мәҗбүр итәргә тиеш түгел. «Виски – кола», мәсәлән, ә анда виски юк. Тагын шунысы да бар: яңа закон сатып алган сырадан сыра эчемлекләре җитештерүне дә тыячак. Мондый исерткечләрне ясау хокукы фәкать сыра җитештерүчеләргә генә биреләчәк. Аны базардан алып, төрлечә бутап сатучыларга юл ябылачак, – диде Максим Топилин.

Белгеч сүзе

Рөстәм ВӘЛИУЛЛИН, табиб-нарколог:
– Яңалык турында ишеттем. Тик үзе утырган ботакны кем чапсын? Алкогольле эчемлекләр сату ул – бизнес. Исемен үзгәртеп кенә, җисеме үзгәрми. Әнә тәмәке кабы тышына да: «Тәмәке тарту – миокард инфарктына сәбәпче», – дип язалар. Тик моңа карап кына беркем дә тартуны ташламый. Киресенчә, көләләр генә. Кибеттә: «Әнә теге, «инфарктлы» тәмәкене бирегез», – дип сорап алганнарын еш ишетәм. Ярар, «наливайка»ларның да исемнәрен үзгәртсеннәр ди. Тик эштән кайтучы кеше юл өстендәге хәмер кибетенә барыбер керәчәк. Чәркә күтәреп куйганнан соң, өйдә ашамый. Чөнки тамак ялгаган бит инде. Әнә шулай организм башка энергия чыганагына ияләшә, авыру барлыкка килә. Илдә профилактика чараларын арттырырга кирәк.

Күбрәк сатканнар

Республиканың Дәүләт алкоголь инспекциясе мәгълүматларына караганда, былтыр Татарстанда исерткеч эчемлекләр сату күләме 4 процентка арткан. Ел дәвамында 6069,3 мең декалитр (1 декалитр = 10 литр) алкогольле продукция сатылган. Шуның 54 проценты – республикага читтән кергән хәмер. Аның күп өлеше ил җитештерүчеләренә туры килсә дә, былтыр Татарстанда импорт шешәгә үрелүчеләр саны арткан. Узган ел республикага якын һәм ерак 69 чит илдән хәмер кергән. Беренче өчлеккә Италия (һәр дүртенче шешә шул илдән кайткан. – **Ред.**), Грузия (19 процент) һәм Әрмәнстан (10 процент) эчемлекләре эләккән.

Татарстан казнасын баетучы Татспиртпром узган ел 10937,3 мең декалитр алкогольле продукциясе, шул исәптән 9502,2 мең декалитр аракы җитештергән.

– 2023 ел дәвамында законсыз әйләнештән 156 мең литр спирт, ялган аракы һәм көмешкә алынды. Нәтиҗәдә 33 кеше – административ, 11 кеше җинаять җаваплылыгына тартылды, – дип сөйләде еллык коллегия утырышында Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов.

Утырышта халык эчкән исерткечләрнең сыйфатына аерым тукталдылар. Шул ук сыраны алсак, әлеге төр продукциянең сыйфатын яхшыртуга аны маркировкалау да ярдәм итәр, дип өметләнәләр. Билгеле булганча, Татарстан тәҗрибә рәвешендәге эштә катнаша. 2023 елның 1 апреленнән бирле республикада сыра, сидр кебек аз градуслы спиртлы эчемлекләр тутырылган зур мичкәләргә тамга сугалар һәм һәр «адым»ын күзәтеп баралар. Киләсе елдан республика тәҗрибәсен ил күләмендә гамәлгә кертәчәкләр.

Җәүдәт Әхмәтхановны республиканың 500ләп торак пунктында спиртлы эчемлекләрне ваклап сатучы сәүдә нокталары булмавы да борчый. «Димәк, биредә сыйфаты тикшерелмәгән хәмер саталар», – диде ул. Узган ел Татарстанда сыйфатсыз хәмер белән агулануның 548 очрагы теркәлгән. 213 кешенең гомере өзелгән.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

БУРЫЧ ЙӨГЕ

pnp.ru

Микрофинанс оешмаларының күбесе тәмле телле булулары белән халык ышанычын яулый. «Биш минут эчендә фәлән сум», «Хезмәт хакына кадәр заем», «Паспорт кына кирәк!» ише җөмләләр кешенең акчага бәйле барлык мәшәкатьләрен дә юк итәр төсле...

Алганны бирә дә бел, ди халык. Акча ягы такыр булып, микрофинанс оешмалары, кредит өләшүче банклар ишегең таптарга мәҗбүр кешеләр саны кимеми, киресенчә, елдан-ел арта гына бара. Моны саннар да раслый. Бурычсыз тормыш бармы? Язмабыз – шул хакта.

2022 ел белән чагыштырганда, 2023 елда «хезмәт хакына кадәр» дип заем алучылар 12,25 процентка арткан. Кредит тарихлары илкүләм бюросы моны рекордлы күрсәткеч, ди. Хәлләрнең ничек үзгәрүен түбәндәге саннардан да чамаларга мөмкин.

РОССИЯДӘ – МИКРОЗАЕМ АЛУ

Кайчан?	Күпме?
2019 ел	16,56 млн
2020 ел	16,7 млн
2021 ел	28,62 млн
2022 ел	31,1 млн
2023 ел	34,91 млн

** НБКИ мәгълүматларына таянып*

Банклар кешегә кредит бирмәскә дә мөмкин әле. Ә микрофинанс оешмалары артыгын төпченеп тормый. Хәер, аларга бу кирәк тә түгел инде. Берне мең итеп кире кайтаралар бит барыбер.

– Банктан кредит алу катлаулырак, – ди финанс белгече Ләйсән Халикова. – Банкта алдан ук кеше турында барлык мәгълүматны тикшерәләр, анализлыйлар. Кайда эшли, нинди милке бар, түли алырмы-юкмы, керемнәре күпме? Микрофинанс оешмаларына кыскача мәгълүмат та җитә. Шуңа да алардан кредит алу җайлы. Банклар Үзәк банк күзәтүе астында тора. Килешүләр төзегәндә дә алар аны җентекләп эшли, чөнки зур хата ясасалар, лицензиядән колак кагулары да бар. Вакытында түләмәсә, кешене судка бирәләр.

Ә микрофинанс оешмаларына килгәндә, аларның күпчелеген СРО (Саморегулируемая организация. – **Ред.**) контрольдә тота. Шул рәвешле, күзәтчелек булмагач, алар үзләренә күп нәрсәне рөхсәт итә. Килешүләрне дөрес төземи, процентларны югары куя һәм башкасы.

Микрозаемнарның мондый үсеше Россия икътисадына да кулай түгел, билгеле. Белгечләр искәрткәнчә, кредитын вакытында түләр өчен яңа кредит алу (закредитованность) банкротлык рәсмиләштергән кешеләр санын арттыруга да китерәчәк.

Әҗәт йөген сөйрәү авырайса, кредит бурычы төп керемнең зур өлешен алып тора башласа, нишләргә? Арбитраж идарәчесе ярдәмчесе, юрист Алсу Әхмәтовадан шул хакта сораштык.

– Бурычларны ничек киметергә соң? Барыбызга да билгеле ысуллар: реструктуризация, кредит каникулы һәм рефинанслау. Әмма сезнең бурыч күләме бик тә зур булып, әҗәт күләмен капларлык дәрәҗәдә хезмәт хакы алмыйсыз икән, 127 номерлы Федераль закон нигезендә физик затларны банкрот итеп тану процедурасын тәкъдим итәм. Бу закон – авыр хәлдә калган кешеләргә зур ярдәм чарасы. Түли алмаган очракта, Арбитраж суды аркылы мөрәҗәгать итсә, кеше шушы кредитлардан азат ителәчәк, – дип аңлатты ул.

Алсу Әхмәтова әйтүенчә, яңа кредит алган вакытта, кеше элегрәк банкротлык рәсмиләштергән булуын хәбәр итәргә тиеш. «Хәер, банклар аны болай да күрәчәк. Кредит тарихында чагыла ул. Банкрот булганнан соң яңа кредит алырга ярамый дигән сүз юк», – дип аңлатты ул.

Сораштыру

КРЕДИТ ТҮЛИСЕЗМЕ? БУРЫЧКА АКЧА БИРӘСЕЗМЕ? УКУЧЫЛАРЫБЫЗДАН ШУЛ ХАКТА СОРАШТЫК.

Зәринә ХӘСӘНШИНА, җырчы:
– Бурычка бирергә дә, алып торырга да яратмыйм, чөнки бу – минем өчен җаваплылык. Бурычка бирми торган кешеләрне саран дияргә яраталар инде. Ә миңа калса, бурычка акча алып, аны кире кайтармаучы саран! Андый очраклар тормышымда булды. Шуңа күрә бурычка да хәзер бары тик иң якын, ышанычлы кешеләремә генә бирәм.
Кредитым, әлбәттә, бар! Кредитсыз һәм ипотекасыз яшәү яшәүмени инде ул, йә! Машинаны кредитка алдым, шөкер, аны җаен түләп бетердем. Шул ук вакытта ипотекам да бар. Хәзер инде анысын түлим.

Искәндәр НУРМИЕВ, медицина хезмәткәре:
– Кредитка мөнәсәбәтем тискәре. Әмма ипотека түлим *(көлә)*. Берсен түләп бетердем, инде икенчесен алдым. Вакытында алып калганмын, дим. Әле өченчесен дә алыр идем, тик хәзер процентлар бик югары. Ә менә кредитка батып, телефон, машина алуларны аңламыйм. Нәрсәгә? Җәяү дә йөреп була, башка мөмкинлекләр дә бар бит. Җитәрлек акчаң юк икән, алмыйча торасың инде, җыйгач сатып аласың. Бу җәһәттән мин шулайрак фикерлим. Бурычка бирү дигәннән, миннән ике көннең берендә акча сорап торалар. Сүз дә юк, сораганга акча биреп торам. Әмма иң яратмаганым – биргән акчаны кешедән сорапып, теләнеп йөрү. Үз акчаңны бит әле ул! Шөкер, соңгы елларда үземнең әҗәткә акча сораганым юк. Сораган очракта да, әти-әни, туганнардан гына. Эшләгәнем җитә.

Рүзәл ШӘРИПОВ, «ТНВ» каналы корреспонденты:
– Бурычка бату начар инде ул. Әҗәтле килеш яшәгәндә, күңел тыныч булмый. Шәхсән үзем, кешенең проблемасы бар икән, бурычка биреп торам. Ләкин бурычка акча алмаска тырышам. Кредитка килгәндә, сатып аласы килгән әйбереңнең суммасы зур икән, дус-иш, туган-тумача гына булыша алмаганда, кая барасың инде. Кредит та – үз урынында файдалы һәм кирәкле нәрсә. Үземнең кредитка нидер сатып алганым юк әле. Дус-ишләрем арасында кредитлы кешеләр шактый. Хәтта 20 яше тулмаганнарның да банкка бурычы бар. Әйтик, кредитка телефон алалар да кичектереп түлиләр.

Раилә ҺАДИЕВА, декрет ялындагы әни:
– Студент вакытта кредиттан рәхәтләнеп файдалана идем. Дөрес, түлисе генә рәхәт түгел иде *(көлә)*. Әти-әнидән артык акча сорамаска тырышып яшәдек. Заказга шигырьләр, мәктәп балалары өчен рефератлар яздым, няня булып та эшләдем, азмы-күпме стипендиям дә булды. Микрофинанс оешмаларына барганым булмады. Барырга да язмасын инде. Анысы – соңгы чиктер, минемчә.
Тәүге тапкыр кредиттан кәттә телефон алу өчен файдаландым. Соңрак ноутбук алдым. Шөкер, икесен дә бернинди штрафларсыз, «просрочка»сыз башкарып чыктым. Кредитсыз яшәп булмый инде ул. Хәзерге заманда бигрәк тә. Адым саен «кредит ал» дип әйдәп торалар, көнозын телевидениедә, радиода, интернетта рекламасы әйләнә. Алмас җирдән алырсың. Хәзерге вакытта икенче машина алырга җыенабыз. Кредитка инде, билгеле.

**Шәхси банк уздырган сораштыруга таянып*

12 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Халкым минем…» 12+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00, 01.40 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 19.10, 22.20, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Кызган казан» 6+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Александр Проханов. Исповедь» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 08.30, 13.05, 15.00, 17.45 Новости.
07.05, 18.50, 21.45, 00.45 Все на Матч!
08.35 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
12.45 Специальный репортаж 12+
13.10 «Есть тема!»
14.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
15.05 «География спорта. Тюмень» 12+
15.35 «Громко»
16.40 Смешанные единоборства. UFC. Джек Хермансcон против Джо Пайфера 16+
17.50 Еврофутбол. Обзор 6+
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Локомотив» – «Спартак»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Удинезе»
01.15 «17 часов до вершины» 12+
01.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Белогорье» – «Локомотив» 6+
04.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.50 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ» 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35, 06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.25 «Порча» 16+
13.00, 01.25 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ТЁМНОЕ ПРОШЛОЕ» 16+
19.00 «ПОРОЧНАЯ СВЯЗЬ» 16+
02.45 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО» 16+

ЗВЕЗДА

04.10 «ЛЕТО ВОЛКОВ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.05 «ТЕКУМЗЕ» 12+
13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 03.25 «ПРИКАЗА УМИРАТЬ НЕ БЫЛО» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ХОЗЯИН ТАЙГИ» 12+
02.35 «Автомобили Второй мировой войны» 16+

---

13 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 18.45 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Дуслык илендә» 12+
17.45 «Таяну ноктасы» 16+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Нефтехимик» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.40 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 00.40, 19.35 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Здоровый образ» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
07.00, 08.30, 12.00, 15.00 Новости.
07.05, 15.35, 21.45, 01.00 Все на Матч!
08.35, 12.05 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
10.55 «Вы это видели» 12+
14.10 Специальный репортаж 12+
14.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
15.05 «География спорта» 12+
16.30 Футбол. Кубок равноправия. «Зенит» – «Сантос»
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА – «Лада»
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала 6+
04.00 Лёгкая атлетика. Мировой тур в закрытых помещениях 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.50 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.25 «Порча» 16+
12.50, 01.25 «Знахарка» 16+
13.25, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.00, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «СЛУЧАЙНЫЙ БРАК» 16+
19.00 «ПРАВО НА ИЗМЕНУ» 16+
23.15 «Понять. Простить» 16+
02.45 «6 кадров» 16+
02.50 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО» 16+
06.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «ЧИНГАЧГУК – БОЛЬШОЙ ЗМЕЙ» 12+
13.25, 19.55 «По горячим следам» 16+
13.45, 03.25 «ПРИКАЗА УМИРАТЬ НЕ БЫЛО» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПРОПАЖА СВИДЕТЕЛЯ» 12+
02.35 «Автомобили Второй мировой войны» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың социаль-икътисадый үсешенә мөһим өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Рәисенең штаттан тыш ниегездә ярдәмчесе **Исхаков** Камил Шамил улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүләре өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең тышкы элемтәләр буенча проректоры **Алишев** Тимерхан Булат улы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөнья тарихы югары мәктәбенең халыкара мөнәсәбәтләр, дөнья сәясәте һәм дипломатия кафедрасы доценты **Вәлиева-Хәкимова** Римма Рафаэль кызы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Физика институты директоры **Гафуров** Марат Ревгер улы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Чит телләр һәм тәрҗемә югары мәктәбенең Европа телләре һәм мәдәниятләре кафедрасы өлкән укытучысы **Морозова** Татьяна Вячеславовна, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Физика институты астрофизика һәм космик геодезия бүлекчәсенең астрономия һәм космик геодезия кафедрасы профессоры **Нефедьев** Юрий Анатольевич, «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт бюджет учреждениесе директоры **Рәхимов** Илнур Сәләйман улы, Татарстан Республикасының Дубайдагы сәүдә-икътисадый вәкиле (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре) **Хәйр** Тимур Иршат улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Зәй икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционер җәмгыяте башкарма директоры **Фәрдиев** Рифгать Мидхәт улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясенең онкология, радиология һәм паллиатив медицина кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы **Гатауллин** Илгиз Габдулла улына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең фәнни-тикшеренү бүлеге мөдире, медицина фәннәре докторы **Хәбибҗанов** Равил Ярхәм улына **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе А.М. Бутлеров исемендәге Химия институтының югары молекуляр һәм элемент-органик кушылмалар кафедрасы профессоры **Галкина** Ирина Васильевнага **«Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе **Байрашев** Павел Андреевичка **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КИҢӘЮ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Варикоз – бүген иң еш очрый торган чирләрнең берсе. Белгечләр чаң суга: соңгы елларда ул яшәргәннән-яшәрә. Бүген хәтта 30 яше тулмаганнар арасында да кан тамырларының киңәюе күзәтелә башлаган. Аннан ничек сакланырга? Варикоз вакытында нәрсәләр эшләргә ярамый?

7 нче номерлы шәһәр хастаханәсенең йөрәк-кан тамырлары хирургиясе табиб-флебологы Сәйфетдин ХИҖРИЕВ шулар хакында сөйләде.

✓Варикоз – гади генә әйткәндә, кан тамырлары киңәю ул. Андый чакта кан тамырлары зәгыйфьләнә, кан әйләнеше бозыла. Әлеге авыру еш кына нәселдән күчә. Ул көн дәвамында утырып эшләү, хәрәкәт җитмәү яки, киресенчә, көн дәвамында аягөсте басып эшләү аркасында да пәйда була ала. Шуңа күрә офиста эшләүчеләр, машина йөртүчеләр, кассирлар, официант, хирурглар арасында варикоз аеруча еш очрый.

✓Йөкле хатын-кызлар арасында да еш очрый торган күренеш бу. Булачак әниләрдә 3–4 тапкыр күбрәк тә күзәтелә әле ул. Ник дигәндә, йөкле хатын-кызның аналыгы зурайганнан-зураеп, янбаштагы кан тамырларына баса башлый. Бу исә аякларга кан килүне кыенлаштыра. Йөкле чакта хатын-кыз организмында барган гормональ үзгәрешләр хәлне тагын да катлауландыра. Шуңа күрә бәби көткән хатын-кызлар сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга тиеш.

✓Варикоз аяклар шешү аркасында да барлыкка килергә мөмкин. Моның сәбәпләре төрле була. Кан тамырларындагы басым артса, кан тамыры җәрәхәтләнсә, ялкынсыну башланса, инфекция эләгү, кандагы аксым күләме кимесә дә аяк шешәргә мөмкин.

✓Без, варикоз аякта гына була, дип уйларга гадәтләнгән. Чынлыкта, варикоз тәннең күп кенә башка өлешләрендә дә була ала. Анда ул көчле авырудан соң өзлегү нәтиҗәсендә килеп чыга.

✓Бу авырудан бары тик хирургия ысулы белән генә дәваланып була. Дарулар авыртуны вакытлыча басып кына тора. Әгәр вакытында дәваламасаң, аякларда тромб пәйда булырга мөмкин.

✓Кайберәүләр кан тамырлары киңәюне сөлек салдырып җиңмәкче була. Әмма бу – зур хата. Ник дигәндә, варикоз вакытында кан тамырлары үзгәрә. Шул сәбәпле кан китү куркынычы да арта.

Кан тамырларын саклау

➤Аяктагы уңайсызлыклар, көзән җыеру, шешенүләр – кан тамыры киңәюнең беренче билгеләре. Әлеге билгеләрнең берсе булса күренсә дә, кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Үз белдегең белән дәвалану куркыныч.

➤Кан тамырлары киңәйгәндә мунчада чабынырга, парланырга ярамый. Спорт белән шөгыльләнгәндә дә көч китермәгез.

➤Озак вакыт аягүрә эшләүчеләргә компрессион трикотаж кияргә киңәш ителә.

➤Йоклаганда аякларыгызны 20–30 градуска күтәреп ятуны гадәткә кертегез. Эштә берничә сәгать эчендә арыйсыз икән, бераз ятып яки 10–15 минутка булса да аякларны өскә күтәреп торырга тырышыгыз.

➤Варикозны кисәтим дисәң, гәүдә авырлыгын да контрольдә тотарга кирәк. Ашаган ризыгыгыз клетчаткага (яшелчә, җиләк-җимеш, кузаклылар һ.б., ярмаларга, майсыз ит ризыкларына бай булсын. Яңа пешкән камыр ризыклары, шикәр, артык тозлы әйберләр организмдагы суны тоткарлый. Нәтиҗәдә кеше шешенергә мөмкин. Бу исә варикоз килеп чыгу ихтималын арттыра.

ВАРИКОЗ ВАКЫТЫНДА ГИМНАСТИКА

Кан тамырлары киңәйгәндә махсус күнегүләр дә ярдәмгә килә. Алар чалкан яткан килеш, аякларны өскә күтәреп ясала. Һәр күнегүдән соң, аякларыгызны төшереп, ял итеп алыгыз. Күнегүне ничә тапкыр кабатлау үзегездән тора.

1. Аяк табаннарын сәгать теле уңаена һәм сәгать теленә каршы юнәлештә әйләндерергә.
2. Аякларны тубыктан бөгәргә һәм турайтырга.
3. Тез буыннарын бөгеп, аякларны сәгать теле уңаена һәм сәгать теленә каршы юнәлештә әйләндергәләргә.
4. Тез һәм оча-бот буыннарын бөгәргә һәм турайтырга.
5. Аякларны туры тотып күтәрергә һәм төшерергә.
6. Велосипедта йөрү хәрәкәтләре ясарга.

ХАЛЫК МЕДИЦИНАСЫ КИҢӘШЛӘРЕ

Каен бөресе. Ярты литрлы банканың өчтән бер өлешенә яңа гына бүрткән каен бөреләре җыеп тутырыгыз. Өстенә спирт яисә аракы салып, ун көн тотыгыз. Шуны көн дә аякка сөртеп, 10–15 минут ятып торыгыз. Моны торып китәр алдыннан кабатлагыз.

Помидор. Пешкән помидорны кисәкләп турагыз да киңәйгән аяк тамырларына каплап, чеметтерә башлаганчы тотыгыз. Помидорларны алгач, аякларны салкын су белән чайкатырга онытмагыз. Дәвалануны тамыр зәңгәрлеге беткәнче дәвам иттерергә кирәк.

Әрем. Бер уч төелгән әрем яфрагы белән орлыгын ярты литр оеган сөткә салып болгатыгыз. Шул боламыкны 3–4 кат марлядан ясалган салфеткага сылап, аякның киңәйгән тамырларына каплагыз. Өстенә полиэтилен ябыгыз да, аякны кечкенә мендәргә сузып куеп, ярты сәгать утырыгыз.

Исеңдә тот!

ҺӘР ИСНЕҢ – ҮЗ ЧИРЕ

Кайчак кеше тәненнән ниндидер ят ис килә башларга мөмкин. Табиблар аларның һәркайсына игътибарлы булырга киңәш итә. Тәннән килгән ят ис чир билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә алар.

Балык исе. Ашкайнату системасындагы үзгәрешләр билгесе булырга мөмкин. Кайчак ашказаны аксымга бай ризыкларны тиешенчә эшкәртеп бетерә алмый. Нәтиҗәдә кешенең сулышыннан, тир һәм бәвеленнән балык исе килә.

Көчле тир исе. Тик утырганда да тирлисезме? Кышкы салкында туңып кайткач та шабыр тиргә баткан буласызмы? Бу сорауларга уңай җавап бирсәгез, сезгә гипергидроз (чамадан тыш тирләү) диагнозы янавы ихтимал.

Ачы ис. Бавыр дөрес эшләмәгәндә күзәтелергә мөмкин. Моңа ашказаны эшләмәү, күңел болгану кебек билгеләр дә өстәлсә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итү хәерле.

Тузан исе. Яшь барган саен организмыбыз да акрынлап гомер козләренә кирәргә әзерләнә башлый. Тәннән килгән тузан исе – картаю билгесе, ди белгечләр.

Саклап куй!

Буыннар авыртканда

Алма серкәсе. 1 стакан алма серкәсен 6 стакан суга салып, кулларны һәм аякларны шунда чылатып алырга кирәк. Әгәр сезне муен, җилкә тирәсендә авыртулар борчый икән, ул вакытта авырткан урынга компресс куегыз.

Шифалы эчемлек. 3 аш кашыгы алма серкәсен 300 грамм суга яисә теләсә нинди җимеш согына кушып болгатырга кирәк. Шуны көненә 3 тапкыр ашар алдыннан эчеп куегыз.

Пар яшәртә

Биткә парлы ваннаны тән тиресе коры булганда елына 2 тапкыр, ә майлы булса, бай саен ясарга киңәш ителә. Мондый ванна тире ныклап чистарсын өчен кирәк. Аны ясау өчен, башны йомшак сөлге белән каплап, кайнар су салынган савытка иелеп торыгыз. Бит белән савыт арасы 10–15 сантиметр булсын. Аннан да якынрак килергә ярамый, битегез пешүе бар. Шулай 10–15 минут торыгыз. Әгәр дә бит тирегез коры икән, парлы ваннадан соң майлы крем сөртегез. Парлы ваннадан соң битне башта җылы, аннан салкынча су белән юарга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Белен тор!

Суган белән йомырка ярата

Суган төнәтмәсе, кәлшәләргә файдалы булудан тыш, дезинфекция дә ясый. Аны әзерләү өчен 5 л суга 20 г суган кабыгы салып, берничә көн төнәтәсе. Аннары төнәтмәне атнага бер тапкыр сибәргә ярый.

Йомырка кабыгы шулай ук үсентеләр өчен файдалы. 3 литрлы банканың 2/3сенә йомырка кабыгы, аның өстенә җылы су салып, 4 көн тотарга. Аннары 1:3 күләмендә су белән болгатып, кәлшәләргә сибәргә.

Бакчачыга

Борычның үңсын

Танылган бакчачы блогер Рәмзия Әхмәдуллина үзе сынап караган, иң яхшы дип тапкан татлы борыч сортларын әйтте. Менә алар:

- *Биг Бой (кызыл)*
- *Биг Мама (сары)*
- *Какаду (сары, кызыл)*
- *Пионер (кызыл)*
- *Ласточка(кызыл)*
- *Пилот (кызыл)*
- *Аллар (кызгылт сары)*
- *Желтая Капея (сары)*
- *Гороспель (сары)*
- *Богатырь (кызыл)*
- *Винни Пух (кызыл)*
- *Желтый бык (сары)*
- *Красный бык (кызыл)*
- *Здоровье (кызыл)*
- *Помпео (кызыл)*
- *Снежок (кызыл)*
- *Купец (кызыл)*

– Сату нокталарында була торган популяр сортлар болар. Кайсыларын сайлап алсагыз да, үкенмәссез. Сорт турында күбрәк орлык кабында язылган була. Мәсәлән, кемгәдер эре, итләч борыч кирәк. Кемдер уртача зурлыктагы, бертигез формалы борычлар ярата. Орлыкларалганда, анысына да игътибар итегез, яме, – ди бакчачы.

Ябыгыйм дисәң

1 Ашаганчы 30 минут алдан бер стакан җылы су эчеп куегыз. Ул ашкайнатуны көйләп җибәрә. Шунлыктан ризык яхшырак эшкәртеләчәк.

2 Ашый торган савытыгыз зуррак булса, кечкенәрәккә алыштырыгыз. Бу үзеңне алдау гына дисәләр дә, нәтиҗәсе үзен сиздерми калмас. Чөнки тәлинкә алыштырып кына да без үзебез дә сизмәстән 30 процентка азрак ашарга күнегә алабыз.

3 Күбрәк хәрәкәтләнергә тырышыгыз. Эшкә килгәндә транспорттан бер тукталыш алдан төшеп җәяү атлау, төшке аш вакытында бераз гына йөреп керү, лифтка кергәнче баскычтан җәяү менү – барысы да ябыгырга ярдәм итә.

ПОМИДОР ТҮГЕЛ, ПАПАЙЯ!

Кукмара районының Зур Сәрдек авылында яшәүче 70 яшьлек Җәүдәт Юсупов бер ел элек папайя үстерә башлаган. Җимешләрен көзгә өлегерер дип көтә. Ә менә ананас, мандарин, лимонын тәмләп караган инде. Авызыгыздан сулар килдеме? Тропик җимешләр үстерүнең сере нинди икән?

Көньяк җимешләре үстереп карау – заманында 34 ел агроном булып эшләгән Җәүдәт абыйның күптәнге хыялы. Җирнең бар нечкәлекләрен белә бит ул. Нигә әле тәҗрибә үткәреп карамаска? Тик кайчандыр үз бакчасы экзотикага әйләнер дип башына да китермәгән. Ә бит барысы да ананастан башланган. Башта туганы биргән үсентене тәрәзә төбендә үстереп караган. Була икән бит! Кышын яктылык җитсен өчен, кибетләрдә сатыла торган шәмәхә лампа элгән. Аннан ананасны бакчага чыгарган. Ул кып-кызыл чәчәк атып, бар дөньяны хуш искә күмгән. Җимеше кибеттәгесеннән дә зуррак! Шушы күңелле мизгелләр аны алга таба тропик бакчачылык белән шөгыльләнергә этәргән. Шри-Ланкага ял итәргә баргач, бу теләге тагын да арткан. Бездә бакча кырыенда кычыткан үсә, ә анда – ананаслар. Агроном кая барса да, үз өлкәсе белән кызыксына. Шундагы ананасларның очын алып кайткан. Дөресрәге, ресторанда сок ясаучы егетләргә, җимешнең очын ташламыйча, җыеп барырга кушкан. Хәзер инде алар ун төпкә җиткән. Көньякныкы күпкә сусыл һәм тәмлерәк икән. Чүлмәкләр санын тагын да арттырмакчы ул. Җылы якка барган саен ятрак, тансыграк җимешләргә кызыга. Папайясы орлыктан тишелгән, җимешләре җитешен килә. Әмма шактый көтәргә туры киләчәк. Анысы – алты төп. Күбрәк тә булган әле. Куе булгач, кискәләгән. Мандариннары бик мул уңыш биргән. Тик тәмгә әчкелтрәк икән. Шулай да ризык әзерләгәндә кулланырга мөмкин. Лимоны да әйбәт кенә җимеш биргән. Хәзер дә 4–5е ботакта өлгереп утыра. Берсе – 250 грамм чамасы. Өч ел элек тотынган экзотик бакчачылыкның нәтиҗәсе шундыйрак. Бу могҗизалар 8гә 4 метрлы теплицада майтарыла. Моннан тыш, җиләге, кыяр-помидоры да бар. Сүз уңаеннан, Юсуповлар күп еллар орлык суганы үстереп сату белән дә шөгыльләнә. Анысы – төп эш, ә бакча – хобби.

– Теплицаны җылыту гына түгел, яктылык та бик мөһим. Баштарак яз көне утырттык, аннан тагын да иртәләдек. Мин үстерәм, ә КАИны бетергән улым Рүзәл техник якларын кайгырта. Теплицаны җылыту, яктырту шактый чыгымлы, – ди Җәүдәт абый.

Яктылыкны көйләсәң, тәрбияләү әллә ни кыен түгел. «Бөтенләй карыйсы да юк», – ди ул. Туфрагы гөлнеке дә ярый. Аны көл белән катнаштырып сала. Кибеттән алынган ашламалар сипми. Көл фосфор, калийны алыштыра. Суны атнага бер генә сипкәли. Кыскасы, экологик яктан чиста ризык ашыйлар.

Ананасны ай саен җимеш бирерлек итеп үстерү хыялы бар Җәүдәт абыйның.

– Мин ананасны сату өчен үстермим. Безгә табыш түгел, ә җимешнең булуы, күзне куандыруы кирәк. Иртән сәгать 5тә торам. Тышта – буран, ә теплицада – җылы, рәхәт. Бөтен нәрсә – чәчәктә. Күңелгә шулкадәр энергия, көч бирә ул. Аларның чәчәк атканындагы исен берни белән дә аңлата торган түгел. Менә шуңа да сөенеп яшим мин, – ди Җәүдәт абый.

Сәрия МИФТАХОВА

Тәмле булсын!

ТАРЫ БЕЛЕНЕ (Раилә Ахунова рецепты)

Кирәк: 1 стакан тары ярмасы, 3 йомырка, 2 стакан сөт, 11 г коры чүпрә, тоз, тәменчә шикәр комы, 4-5 аш кашыгы үсемлек мае, он.

Тары ярмасын юып, тоз салып, суда пешереп алдым, җылы сөткә шикәр комы, чүпрә, ярманы салып бераз тоттым. Йомырка, үсемлек маен, тоз он кушып, белен камыры кебек болгатабыз. 30–40 минутта кабарып менә һәм пешерәбез.

Укучы киңәше

Кабак белән әфлисунлы кайнатма

Моңа кадәр дә кабак, әфлисун, лимоннан вареньены еш кайната идек. Тәмле дә, файдалы да бит. Аларның һәммәсен ваклап турап, шикәр комы салып, болгатып куеп, берничә сәгать тота һәм кайнап чыккач, акрын утта, лимон кабыгы йомшарганчы пешерә идек.

Кабып ашарга, чәйнәп эчәргә яратучыларга шәп иде ул вариант. Күптән түгел яңа рецепт бирделәр. Анысы бик җайлы һәм тиз булып чыкты. Зур кабакның яртысыннан бөккән һәм бәлеш пешердек тә калганын иттарткычка сыярлык итеп телемләп кистек. Алты лимон һәм сигез әфлисунны да, орлыкларын алып, бүлгәләдек. Аларын да иттарткычтан үткәрәсе.

Барлыкка килгән куе массага бер килограмм тирәсе шикәр комы салып, болгатып, кайнап чыккач, биш-ун минут тирәсе сүрән утта пешерәсе. Аннан, тәмләп карый-карый, үзегезгә кирәк кадәр шикәр комы сала-сала, ул эреп беткәнче болгаткалап торасы («пятиминутка» карлыган вареньесы кайнаткандагы кебек). Куе, бик тәмле варенье килеп чыга. Эшләп карагыз әле, үзе тиз, үзе тәмле.

Гөлсинә ЯРУЛЛИНА

МАКТАНУ БУЛМАСЫН

shutterstock.com

Намаз – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, бик зур бүләге. Адәм баласының күңеленә рәхәтлек бирә, җанына тынычлык иңдерә торган изге гамәлләрнең берсе дә ул. Бүгенге сәхифәбезне исламның икенче баганасы саналган намазга бәйле сорауларга багышларга булдык.

Аларга «Шамил» мәчете имам-хатыйбы Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН ачыклык кертте.

:: Соңгы арада намазны кешегә күрсәтеп уку модага әверелеп китте кебек. Моның белән бигрәк тә блогерлар мавыга. Намазны шулай кешегә күрсәтеп ачыктан-ачык, бәлки, хәтта мактанып уку дөресме? Бу гөнаһ саналамы?

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Һәрбер эшләнә торган эш кешенең ниятенә нигезләнә», – дигән. Әгәр кеше тышкы яктан нинди дә булса бер изгелек (намаз уку, хәер бирү, хаҗга бару, ураза тоту һ.б.) эшләсә, әмма күңеленнән моны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен башкармаса, ул гамәлләренә әҗер-савап бирелми. Кеше бу изгелекләре белән Аллаһының рәхмәтенә ирешә алмый. Шуңа күрә намаз уку гына түгел, бөтен гамәл-гыйбадәтләребез фәкать Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен генә эшләнергә тиеш. Коръәни Кәримдәге бер аятьтә Аллаһы Тәгалә: «Вәил җәһәннәме булсын шул кешеләргә, кемнәр намазларын игътибарсыз укыйлар, кешеләр күрсен өчен дип намазларын башкаралар», – ди. Шуңа күрә кеше намаз-гыйбадәтенә игътибарлы булырга, аны җиренә җиткереп үтәргә тырышырга тиеш. Намазны кеше күрсен өчен башкарырга ярамый. Намаз укыганны яздырып, интернет челтәренә кую бары бер очракта гына рөхсәт ителә. Әгәр кеше моны башкаларга нәсыйхәт булсын, алар шуны күреп һәвәсләнсеннәр, үзләре дә өйрәнсеннәр дигән ният белән эшли икән, ул очракта бу дөрес була. Әгәр ул бу эшне мактану, социаль челтәрләрдәге язылучылар, «лайк»лар санын арттыру өчен эшли икән, бу дөньяда сөенечкә ирешмәячәк, ахирәттә дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан зур шелтә алачак.

:: Намаз укый башлагач, аны кисәк кенә ташлаган, намаз укымый башлаган кешене ни көтә?

– Пәйгамбәребез хәдисләренең берсендә: «Намаз ул – диннең тērәге. Кем аны башкарса, динен торгызган булыр. Кем дә кем белә торып намазын ташласа, динен тәрәксез калдырып, җимергән булыр», – дигән. Шуңа күрә намазны белә торып калдыру иң зур гөнаһларның берсе санала. Белә торып намазын укымый яшәүче нечкә генә җеп өстеннән йөргән кешегә охшаш. Ул, бер дә көтмәгәндә егылып, өзелеп, аска тәгәрәп, һәлак булырга мөмкин. Шул рәвешле намазсыз яшәгән кеше мәңгелек ахирәткә имансыз китеп, Аллаһның ачуына дучар була ала. Бу сүз намазын белә торып укымаган һәм намазын бөтенләй ташлаган кешегә дә кагыла.

:: Намаз укыган кешенең алдыннан узып китсәң, ул кешенең намазы кабул булмый, диләр...

– Намаз укыган кешенең каршыннан берәрсе үтеп китсә, әлеге хәрәкәт намаз укучы кешенең намазына бернинди зыян китермәс һәм ул кешенең намазы да бозылмас. Ләкин белә торып шуны эшләгән кеше зур гөнаһ эшләгән булыр.

:: Укучыбызның шундый соравы бар: «Иртәнге намазга кадәр тәһәҗҗүд намазы укый идем. Витр намазыннан соң нәфел намазы укылырга тиеш түгел дип ишеттем. Дөресе ничек икән?»

– Әгәр иртәнге намазның вакыты чын-чынлап кермәгән булса, тәһәҗҗүд намазын уку рөхсәт ителә һәм ул дөрес була. Витр намазыннан соң башка намаз укырга ярамый дигән сүз шәригать хөкемнәренә туры килми. Ягъни витр намазыннан соң да нәфел гыйбадәтләрен башкарырга рөхсәт ителә. Ләкин, галимнәрнең әйтүе буенча, иң хәерлесе – йоклар алдыннан вәҗиб намазыннан соң бүтән намаз укымау.

:: Интернет, социаль челтәрләрдәге видеоларны карап, намаз укырга өйрәнү дөресме?

– Намаз укырга өйрәнгән вакытта иң хәерлесе – үзегезнең янда булган мәчеткә мөрәҗәгать итеп, анда булган муллалардан, абыстайлардан өйрәнү. Ник дигәндә, интернет челтәрендә тәкъдим ителгән видеодәресләрдә дөрес өйрәтәләрме-юкмы икәнен белеп булмый. Шуңа күрә дин дәресләрен интернет челтәреннән өйрәнү ике яклы. Анда кеше намазны хаталы итеп укырга өйрәнергә яки безнең мәзһәбкә туры килмәгән намаз уку рәвешләрен үзләштерергә мөмкин.

:: Көзге каршында намаз укырга ярыймы?

– Дин галимнәре әйтүенчә, намаз укыган кешенең каршында бернинди сурәт булырга тиеш түгел. Әгәр без көзге каршында намаз укыйбыз икән, анда безнең сурәтебез чагыла. Каршыда сурәт булган хәлдә намаз укыган кешенең намазы бозылмаса да, мәкруһ булып санала. Шул рәвешле кеше әлеге гамәле белән намазга тиешсез бер хәрәкәтне керткән була.

:: Намазлык, намаз укыганда киелгән күлмәк башка кулланып булмаслык дәрәҗәдә искерсә, аны ни эшләтергә?

– Әгәр кием искерә һәм аны башкача кулланып булмау хәленә төшә икән, кеше аннан ничек теләсә, шулай котылырга мөмкин. Шулай да кулланылмый торган өс-башны яндырып, күмү хәерлерәк. Намаз укыган киемме ул, гадәти киемме – аерма юк. Намазлыкка килгәндә, ул – намаз укыган кешенең баскан җире һәм сәҗдә кылган урыны чиста-пөхтә булсын дигән шартны үтәр өчен куллана торган җәймә. Хәзерге заман намазлыклары элекләренннән бик нык аерыла. Элегрәк гыйбадәт кыла торган урын чиста булса, намазлык, гомумән, кулланылмаган. Булган очракта да бу намазлыкларның өстенә бернинди язу да, сурәт тә ясалмаган. Хәзергеләрендә исә мәчет сурәтләре дә, нинидер гарәпчә язулар да очрый. Шуңа күрә, әгәр намазлык искергән һәм аның өстендә бернинди сурәт, язу да юк икән, кеше аны көнкүрештә кулланса да була. Искереп беткән намазлыкны машина тәрәзәсен сөрткәндә, идән юганда кулланырга мөмкин. Әгәр таушалган намазлык өстендә мәчет сурәте, догалар бар икән, бу очракта аны яндырып, күмәргә кирәк.

Коедагы ишәк кыйссасы

Бер кешенең ишәге тирән коега егылып төшә. Хуҗа аны ничек чыгарырга белмичә аптырап торганда, ишәк кызганыч авазлар белән кычкыра башлый. Ниһаять, ул шундый карарга килә: ишәк барыбер карт инде, аны чыгару өчен күп көч түгеп маташмаска да була. Коены да күмәргә вакыт. Ул үзенә ярдәмгә авылдан берничә ир-атны, күршеләрен чакыра.

Болар кулларына көрәк алып, барысы да коега балчык ата башлыйлар. Ишәк моны күреп, коточкыч тавышлар чыгара һәм бераздан тынып кала. Тагын берничә көрәк балчык аткач, хуҗа кеше башын аска сузып карый һәм нык гаҗәпкә кала. Ишәк һәр аткан балчыкны нинди гайре табигый көч белән сыртыннан кагып төшерә бара һәм туфрак аның аягы астына өелә. Ишәк җирне таптый-таптый өскә күтәрелә. Хуҗаның иптәшләре туфрак атуны дәвам иттерәләр. Ә ишәк һәр атылганын өстеннән селкеп төшерә тора. Бераздан бөтенесе дә тораташтай катып калалар: ишәк өскә сикереп чыга да урман ягына чаптырып китеп тә бара.

Тормыш барышында әшәкелекләр, батырырга теләүчеләр күп булырга мөмкин. Әмма өстегезгә пычрак төшкән саен, селкенеп алып, һәрвакыт өскә күтәрелегез. Шулай иткәндә генә тормыш коесында батып калмассыз. Авырлыкларга бирешмәгәндә генә коеларның иң тирәннәреннән дә чыгып була.

Йәгез, бер дога!

КӨЧ-КУӘТ СОРАП УКЫЛА

«Ләә-хәулә үәләә куввәтә илләә Билләәәһ».

Бу зикер-дога җәннәт хәзинәсеннән. Ул кешегә көч-куәт бирә, шайтан зыяныннан саклый. Иманлы кешеләргә иң азы йөз тапкыр әйтергә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

БАЛАЧАК КЫШЫ

Быелгы кыш кирәген бирә! Кемдер кар күплектән зарлана, кемдер балачак кышын искә ала... Ул чакта кар көртләре – биегрәк, кары да күбрәк тоелган. Сәхифәбез кунаклары белән мәшәкатьле кыштан әнә шул рәхәт кышка кайтып килдек.

«Юкка түгелдер...»

Тинчурин театры актрисасы **Резеда СӘЛАХОВА** кышкы физкультура дәресләрен искә алды. «Балачагым Залесный бистәсендә узды. Без физкультура дәресләрендә чаңгыда түгел, тимераякта шуа идек. Ул дәресләр шундый ошый иде миңа! Ә мәктәптән соң бияләйләр, өс киемнәре катып беткәнче тау шуган чаклар – бөтенләй дә онытылмас мизгелләр», – ди ул. Гаиләләрендә тагын бер гадәт булган аларның. «Йоклар алдыннан әни апам белән икебезне һава суларга алып чыга иде. Башта – ул безне, аннан без аны чанага утыртып йөртә идек. Апам алдан тарта, мин арттан этәм...» Быелгы кышның шулкадәр карлы булуы юкка гына түгелдер, ди актриса. «Гаҗәп кыш бит! Аллаһы Тәгалә юкка гына шуның кадәр күп кар яудырмыйдыр. «Әй, кешеләр! Бераз акрынаегыз, туктагыз, артык чабасыз, дөньяны артык куасыз», – дияргә телидер ул, бәлки...»

«Бу кадәр булганны хәтерләмим...»

Баянчы **Динар БӘДРЕТДИНОВ**ка да бу кыш балачагын хәтерләтә. «Элек без чанада гына түгел, ләгәнгә дә утырып шуа идек. Анысы аеруча кызык була иде аның», – дип искә ала ул. Рәхәт мизгелләрне искә алу да рәхәт шул. «Элек кар күп була иде, ләкин бу кадәр булганын хәтерләмим. Әллә онытылган гынамы? Ничек булса да, кышны бик яратам. Әле дә чаңгыга баскалыйбыз», – дип сөйли Динар.

«Без шуа торганы аннан да биек...»

ТНВ корреспонденты **Фәйрүзә МӘҖИТОВА** быелгы кышны балачак кышына охшата. «Элек ул авыл урамнарындагы карның күплеге иде. Трактор эттереп киткәч, бата-чума кар ерып йөрү бетә, юл ачыла... Юлның ян-якларында таулар хасил булып кала иде. Бие-е-ек таулар! Өй түбәсенә кадәр җитә иде кар көртләре. Ә без шуа торган тау аннан да биегрәк иде», – дип искә ала ул. Таудан шуу – үзе бер вакыйга. «Мәктәптән кайтып, өй эшләрен эшләгәч, рәхәтләнеп Чирмешән елгасы яры буена таудан шуарга чыга идек. Бөтен бала-чага шунда җыела. Икешәр-өчәр бала бер чанага катлы-катлы ятып та төшә идек», – дип сөйли журналист. Бервакыт, чана шуганда аягын авырттырып, ике атналап өйдә ятарга туры килгән. «Эх, үзем өйдә, йөрәгем чыр-чу килгән балалар янында. Ул елны яз иртәрәк килде: мин терелеп чыкканчы, кар эреп бетте. Чирмешәндә ташу иде инде. Хәзер кар яуган саен, бу – безнең балачак кышы бит, дип куанам», – ди ул.



«Буран булса, сөенә идек»

Чаналы, чаңгылы, кар каткан бияләйле. Җырчы **Ризат РАМАЗАНОВ** та балачак кышын әнә шулай искә ала. «Быелгы кыш, дөрестән дә, кирәген бирә. Ә балачакта, буран башланса, сөенә идек. Мәктәпкә барасы юк бит!» – ди ул. Уеннан башка мәшәкать булмаган чаклар сагындыра, ди җырчы. «Кардан «штаб» ясап, шунда качып ята идек. Өйдән тәмле ризык алып чыгып, шунда утырып ашый идек. Ул мизгелләр сагындыра. Рәхәт вакытлар! Ускәч кенә аңлыйсың шул. Ә ул вакытта тизрәк үсәсе килә иде», – ди Ризат.

Бик беләсегез килсә...

...билгеле бер җырның билгеле бер өлешенең башта яңгырап торуы «колак суалчаны» дип атала. Фәнни телгә күчерсәк, «инволюнтар музыкаль образ» була.

Күпләргә таныш хәлдер: каяндыр ишеткән ниндидер җырның бер өлеше башка кереп кала да, көнозын шуны көйләп йөрисең. Иң ачуны китергәне – ул җыр сиңа бөтенләй ошамаска мөмкин, ә баштан чыгарып ташлап булмый.

Галимнәр бу күренешкә атама да биргән, аны аңлатырга да тырышкан. Күп очракта «колак суалчаны» ул – бик гади, примитив дәрәҗәгә якын көйләр. Алар баш миенә тизрәк кереп урнаша. Хәзерге җырларның да әнә шундый көйләргә салынуына аптырарлык түгел.

Галимнәргә ышансаң, арыган вакытта яки стресс кичергәндә тыңлаган җырлар да тизрәк истә кала. Андый чакта без уй-фикерләребезне контрольдә тота алмыйбыз, ә баш миенә шул гына кирәк. Эштән кайтканда радио тыңлыйсызмы? Анда яңгыраган җырларны кабатлап җырлап йөрисезме? Менә сәбәбе.

Башка «колак суалчаны» кереп оялый торган очраклар моның белән генә бетми. Алар турында киләсе саннарда сөйләшербез.

Аннан-моннан

Узып баручы атнаниләр белән истә калачак? Бу сорауга җавап итеп, социаль челтәрләрдәге «кайнар» яңалыкларны тупладык.

Винарис Ильегет гаиләсендә югалту. Энисенең сеңлесе Заһидә ханым вафат булган. «Минем соңгы апам китте. Гаиләнең тагын бер җебе өзелде. Урыны җәннәттә булсын!» – дип яза җырчы социаль челтәрдәге битендә.

Татар хатын-кызлары – комиксларда. Казанда Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Сара Садыйкова, Сара Шакулова, Мәгубә Сыртланова турындагы «Татар хатын-кызлары» комикслар җыентыгын тәкъдим иттеләр. Җыентыкның авторлары – Рәдиф Кашапов һәм Регина Гаязова, рәсемнәрен исә Наталья Якунина (Уфа), Юлия Галиәкбәрова (Казан), Руслан Ибраһимов (Казан) һәм Арина Филиппова (Раменское) ясаган.

Дүртенче тапкыр әни! Җырчы Лилиана Илназарованың дүртенче баласы – кызы туган. Хәзер ул – өч малай һәм бер кыз әнисе. Яңа туган сабыйның исеме – Лия.

Хәния Фәрхинең кульязмасы табылган. Әфганстан вакыйгаларына багышланган җыр язылган анда. Кульязманы җырчының сеңлесе Фирүзә Ибәтуллина үзенең мәктәп елларында алып барган язмалары арасыннан тапкан.

Премьера арты премьера. Бу атнада Тинчурин театрында – «Җан Баевич» (Гаяз Исхакый әсәре буенча), Камал театрында «Дуслар җыелган җирдә» (Туфан Миңнуллин әсәре буенча) спектакльләренең премьерасы узды. Күрүегезчә, театрларда классикага мөрәҗәгать итү тенденциясе саклана. Алга таба ни булыр...



14 февраль | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
11.00, 00.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 00.25 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Азбука долголетия» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кызган казан» 6+
18.00 «Гаилә учагы» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Соотечественники» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
01.15 «Кәмит Җәвит» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
09.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
10.00 «Халкым минем» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 04.20 «Сөйләшергә вакыт» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Кәмит Җәвит» 16+
20.00, 00.15 «Гаилә учагы» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Здоровый образ» 12+
06.30 Фрирайд. Мировой тур 6+
07.00, 08.30, 13.05, 15.00, 17.55 Новости.
07.05, 15.35, 21.45, 01.00 Все на Матч!
08.35 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
11.45, 18.00 Футбол. Лига чемпионов 6+
12.45 Специальный репортаж 12+
13.10 «Есть тема!»
14.30 «Вид сверху» 12+
15.05 «География спорта» 12+
16.40 «Короли. Воля к победе» 12+
19.00 Футбол. Winline Зимний кубок РПЛ. «Спартак» – «Кайрат»
22.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/8 финала
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Пари Нижний Новгород» – МБА 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.50 «ФАЛЬШИВЫЙ ФЛАГ» 16+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.55, 00.30 «Порча» 16+
13.00, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 01.55 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «КОГДА ТЫ МАМА» 16+
19.00 «ДРУГОЙ МУЖЧИНА» 16+
02.45 «6 кадров» 16+
03.05 «ЗА ПЕРВОГО ВСТРЕЧНОГО» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.15 «ВОЖДЬ БЕЛОЕ ПЕРО» 12+
12.50, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
13.25, 03.50 «МАРШ БРОСОК. ОСОБЫЕ ОБСТОЯТЕЛЬСТВА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Вторая мировая: пламя и сталь» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Секретные материалы» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПРЕДВАРИТЕЛЬНОЕ РАССЛЕДОВАНИЕ» 12+
02.35 «НЕПОБЕДИМЫЙ» 12+

15 февраль | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ӘЛЛӘ ЯЛГЫШ, ӘЛЛӘ ЯЗМЫШ» 16+
13.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Память сердца» 16+
14.15 «Азбука долголетия» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15, 00.25 «Точка опоры» 16+
18.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Металлург» (Мг) 6+. По окончании – «Погружение на 100» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «НЕИЗВЕСТНЫЙ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Җырлыйк әле!» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 04.20 «Кәмит Җәвит» 16+
09.30 «Гаилә учагы» 16+
10.00, 20.00 «Кызган казан» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
18.20, 23.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
21.25, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 Проект «Цивилизации» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ВЕЛИКАЯ. ЗОЛОТОЙ ВЕК» 12+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 12+
03.50 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Здоровый образ. Борьба» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 08.30, 13.05, 15.00, 17.55 Новости.
07.05, 15.35, 20.00, 01.00 Все на Матч!
08.35 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
12.45 Специальный репортаж 12+
13.10 «Есть тема!»
14.30 «Большой хоккей» 12+
15.05 «География спорта» 12+
16.40 «Короли. Чемпион никогда не сдаётся» 12+
18.00 Футбол. Лига чемпионов. Обзор 6+
19.00 «Вы это видели» 12+
20.30 Футбол. Лига Европы. Раунд плей-офф 6+
04.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Белогорье» – «Зенит» 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ШЕФ. МУЖСКАЯ РАБОТА» 16+
22.15 «СПЕЦБАТ» 16+
00.55 «Поздняков» 16+
01.05 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
02.05 «Три танкиста» 16+
02.50 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.25 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.30 «Знахарка» 16+
13.30, 02.00 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.25 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «НЕОКОНЧЕННАЯ СВАДЬБА» 16+
19.00 «СЕКРЕТЫ ЛИЗЫ» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «6 кадров» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 01.10 «БРАТЬЯ ПО КРОВИ» 12+
13.25, 03.55 «МАРШ-БРОСОК. ОХОТА НА «ОХОТНИКА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «В знании – сила, в красоте – спасение, в служении – судьба» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Код доступа» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «КОНТРАБАНДА» 12+
02.35 «ЖАРКОЕ ЛЕТО В КАБУЛЕ» 16+

16 февраль | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести ПФО»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16+
13.00, 03.55 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Наши герои» 16+
14.45, 01.00 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.30 «Кто мы татары?» 12+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Юлчы» 16+
22.10 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.10 «ГРЕЙС И ДЖО. ИСТОРИЯ ЛЮБВИ» 12+
01.25 «Фолиант в столетнем переплете» 16+
01.40 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК» 16+
03.10 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 18.20, 23.10, 04.20 «Ком сәгате» 16+
09.30, 16.30 ,00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.00, 20.30, 02.00 «Заман көзгесе» 6+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 01.05 «Рәгыйдә – яшен яшьнәү» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 21.55 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
21.25 «Кто мы татары?» 12+
19.10, 22.15, 02.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.30 «Илһам – вдохновение» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.45 «Голос» 12+
23.30 «Матадор» 16+
00.30 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Судьба человека» 12+
16.30 «Прямой эфир» 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе! Хором!» 12+
00.30 «Истории Большой Страны» 12+
01.25 «ФРАНЦУЗСКАЯ КУЛИНАРИЯ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Третий тайм» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 09.40, 13.05, 15.00 Новости.
07.05, 15.05, 19.30, 22.00, 01.00 Все на Матч!
09.45 «Небесная грация» 0+
10.05 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
12.05 Футбол. Еврокубки 6+
13.10 «Есть тема!»
14.30 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
15.30, 04.00 Смешанные единоборства. One FC
20.00 Профессиональный бокс. Ночь Чемпионов IBA
22.55 Футбол. Чемпионат Италии
01.55 Лёгкая атлетика. Мировой континентальный тур 6+

НТВ

04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «Прошу, прости!» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 «ЗАХВАТ» 16+
21.40 «СПЕЦБАТ» 16+
00.00 «Своя правда» 16+
01.55 «Квартирный вопрос» 0+
02.45 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+
03.20 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.45 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.55 «Порча» 16+
12.50, 01.50 «Знахарка» 16+
13.25, 02.15 «Верну любимого» 16+
14.00 «Голоса ушедших душ» 16+
14.35 «ПОБЕГ В НЕИЗВЕСТНОСТЬ» 16+
19.00 «ТАЙНЫЕ МЕЧТЫ АЛИСЫ» 16+
23.15 «Уютное утро» 16+
02.40 «КАРТА ПАМЯТИ» 16+
05.40 «НЕЛЮБИМЫЙ МОЙ» 16+

ЗВЕЗДА

07.45, 09.20 «СИЛЬНЫЕ ДУХОМ» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
12.20, 13.25 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
14.35 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ» 16+
15.00 Военные новости 16+
19.40 «Загадки века» 12+
20.30 «Скрытые угрозы» 16+
21.20 «Специальный репортаж» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
23.30 «Музыка+» 12+
00.55 «ВОКЗАЛ ДЛЯ ДВОИХ» 12+
03.15 «КОНТРАБАНДА» 12+
04.45 «Перелом. Хроника Победы» 16+
05.10 «АЛЕНЬКИЙ ЦВЕТОЧЕК» 6+

17 февраль | Шимбә

ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00, 03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30, 01.00 «Музыкальный майдан» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
13.30 «Гаилә учагы» 16+
14.00 «Аклык» 12+
16.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
16.30 «Дуслык иленд» 12+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Спартак» – «Ак барс» 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «МОЛОДОСТЬ ПО СТРАХОВКЕ» 16+
23.30 «МАРУСЯ» 12+
01.25 «УЕННАН УЙМАК» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Рәгыдь – яшен яшьнәү» 16+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05 ,03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Синең өчен сөюләрем» 16+
17.15 «Калеб» 6+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Ничек сезнең хәләрегез?» 16+
22.30 Т.Миңнуллин. «Нәзер». Т. Миңнуллин исемендәге Тубән Кама татар дәүләт драма театры спектакле 16+
00.50 «УЕННАН УЙМАК-2» 16+
04.40 «Заман көзгесе» 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ
06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости
10.15 «Наше всё» 12+
11.05 «ПроУют» 0+
12.15 «Поехали!» 12+
13.25 «Правдивая история. Тегеран-43» 12+
15.35 «Горячий лед». Фигурное катание. Спартакиада сильнейших 2024. Финал Гран-при 0+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.20 «Эксклюзив» 16+
20.05 «Кто хочет стать миллионером?» 12+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 «СТОРОЖ» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Вести. Местное время
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 «В кругу друзей»
12.50 «Доктор Мясников» 12+
14.50 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «СВОЯ ЧУЖАЯ ДОЧЬ» 16+
00.40 «СЕРДЕЧНЫЕ РАНЫ» 12+
04.10 «АРИФМЕТИКА ПОДЛОСТИ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. One FC
08.00, 08.30, 14.20, 17.50 Новости.
08.05, 13.55, 16.15, 19.30, 22.00, 00.45 Все на Матч!
08.35 «Команда МАТЧ» 0+
08.40 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
14.25 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Синара» – «Норильский никель»
17.20 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
17.55 Скоростной спуск на коньках. Гран-при Москвы
19.55 Футбол. Чемпионат Италии
01.25 «Формула-1. Гаснут огни» 12+
01.55 Бокс. Bare Knuckle FC 16+
04.00 Футбол. Чемпионат Германии 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.25 «Жди меня» 12+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 16+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Основано на реальных событиях» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
19.00 «Центральное телевидение»
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.20 «Секрет на миллион» 16+
23.25 «Международная пилорама» 18+
00.10 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.50 «Квартирник НТВ у Маргулиса». IVAN 16+
02.10 «Дачный ответ» 0+
03.05 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
09.30 «Уютное утро» 16+
10.00, 02.40 «СТРАСТЬ» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.45 «СОЗВУЧИЯ ЛЮБВИ» 16+
05.55 «НЕВЕСТА» 16+

ЗВЕЗДА
06.20 «ВОЛШЕБНАЯ ЛАМПА АЛАДДИНА» 6+
08.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.20 «ЖЕНИТЬБА БАЛЬЗАМИНОВА» 12+
11.10 «Легенды музыки» 12+
11.40 «СССР. Знак качества» 12+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «Легенды кино» 12+
14.00 «Главный день» 16+
14.50 «Время героев» 16+
15.10 «Стать «Барсом»: Путь добровольца» 16+
15.55 «Специальный репортаж» 16+
16.20 «По горячим следам» 16+
16.45, 19.25 «КОМАНДА 8» 16+
21.35 «КАЛАШНИКОВ» 16+
23.55 «БЕРЕМ ВСЕ НА СЕБЯ» 12+
01.25 «СИЛЬНЫЕ ДУХОМ» 12+
04.25 «Часовые памяти» 16+

18 февраль | Якшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
08.00 Местное время. Воскресенье

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 01.10 «Дусларыма җырларым» 16+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 Мультфильмы 6+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Кызган казан» 6+
11.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 Әлфия Авзалованың 90 еллыгына багышланган концерт 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00, 22.00 «Семь дней» 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
21.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
23.00 «КЛУБ ЛЮБИТЕЛЕЙ КНИГ И ПИРОГОВ ИЗ КАРТОФЕЛЬНЫХ ОЧИСТОК» 12+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+
05.50 Татарстан хәбәрләре 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять»
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 «Кто мы татары?» 12+
08.00 «Җаным җырда» 16+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 6+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Күңел эретерлек сүзләр бар» 16+
15.40 «УКСЕЗЛӘР» 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 М.Гыйләҗев. «Оҗмах капкасы». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.05 «Повара на колесах» 12+
12.15 «Видели видео?» 0+
14.00 «ВЛЮБЛЕН ПО СОБСТВЕННОМУ ЖЕЛАНИЮ» 12+
15.45 Фигурное катание. Спартакиада сильнейших 2024 0+
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «АБРЕК» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
06.10, 01.30 «ЗОЛОТЫЕ НЕБЕСА» 16+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «КОРОЛЕВА ДОРОГ» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ
06.00 Смешанные единоборства. UFC
08.50, 10.45, 12.25 II Всероссийская спартакиада по зимним видам спорта
11.55, 01.25 Биатлон с Дмитрием Губерниевым 12+
14.20 Новости.
14.25 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Тюмень» – «Кристалл»
16.15, 19.30, 22.00, 00.45 Все на Матч!
16.30 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Матч звёзд»
19.55 Футбол. Чемпионат Италии
01.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит» – «Динамо-ЛО» 6+
04.00 Футбол. Чемпионат Германии 6+

НТВ
04.50 «УГРО» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.00 «Сегодня»
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Маска» 12+
23.55 «Звезды сошлись» 16+
01.25 «Основано на реальных событиях» 16+
03.15 «КОДЕКС ЧЕСТИ» 16+

ДОМАШНИЙ
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ДОБРОТА» 16+
22.55 НЕЛЮБИМЫЙ МОЙ 16+
02.45 «СТРАСТЬ» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
05.30 «КРАПОВЫЙ БЕРЕТ» 16+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Легенды армии» 12+
11.30 «Легенды госбезопасности» 16+
12.20 «Война миров» 16+
13.10 «Код доступа» 12+
14.00 «Скрытые угрозы» 16+
14.50 «Секретные материалы» 16+
15.40 «Загадки века» 12+
16.30 «Улика из прошлого» 16+
17.20 «Специальный репортаж» 16+
18.00 Главное 16+
20.00 «Легенды советского сыска» 16+
22.35 «Москва фронту» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «КАЛАШНИКОВ» 16+
01.50 «ВЫКУП» 12+
03.30 «КОМАНДА 8» 16+

Приложение
к постановлению Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан
от 07 февраля 2024 г. № 37/279

ИНФОРМАЦИОННОЕ СООБЩЕНИЕ
О СБОРЕ ПРЕДЛОЖЕНИЙ ПО КАНДИДАТУРАМ ДЛЯ ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ЗАЧИСЛЕНИЯ В РЕЗЕРВ СОСТАВОВ УЧАСТКОВЫХ ИЗБИРАТЕЛЬНЫХ КОМИССИЙ ИЗБИРАТЕЛЬНЫХ УЧАСТКОВ, ОБРАЗОВАННЫХ НА ТЕРРИТОРИИ КИРОВСКОГО РАЙОНА ГОРОДА КАЗАНИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет сбор предложений по кандидатурам для дополнительного зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий избирательных участков, образованных на территории Кировского района города Казани Республики Татарстан, в период с 10 февраля 2024 года по 13 февраля 2024 года с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов).

Наименование территориальной избирательной комиссии (ТИК)	Адрес территориальной избирательной комиссии
ТИК Кировского района г. Казани РТ	420095, г. Казань, ул. Восстания, д. 82, тел.: (843) 223-29-99, добавочный (3781)

В резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются кандидатуры, не соответствующие требованиям, установленным пунктом 1 статьи 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации».

Кандидатуры, в отношении которых отсутствуют документы, необходимые для зачисления в резерв составов участковых избирательных комиссий, в резерв составов участковых избирательных комиссий не зачисляются.

Примечание.

При внесении предложений по кандидатуре в резерв составов участковых избирательных комиссий на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий».

Постановление Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 5 декабря 2012 года № 152/1137-6 «О порядке формирования резерва составов участковых комиссий и назначения нового члена участковой комиссии из резерва составов участковых комиссий», а также образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» в разделе «Избирательные комиссии» в подразделе «Резерв составов участковых комиссий» «Дополнительное зачисление в резерв составов участковых избирательных комиссий 2024 года» https://izbirkom.tatarstan.ru/.

Центральная избирательная комиссия
Республики Татарстан

Белдерү

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе (массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык ПИ № ТУ 16 – 01758, 2023 елның 23 августында бирелгән) хәбәр итә: 2024 елда Россия Федерациясе Президентын сайлауга бирелә торган түләүле басма мәйданны бүлү буенча жирәбә 2024 елның 15 февралендә (10.00 сәгатьтә башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Казан ш., Академия ур., 2 й., 4 кат, № 416 офис

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

ГАЛИМ БУЛЫП ТУГАНМЫ?

ЯШЬЛӘР ФӘНГӘ ЗУР ӨМЕТЛӘР БЕЛӘН КИЛӘ

Хайваннарда баш мие яман шешен яңача ачыклау, һава шартларына чыдам бодай сортларын үстерү өчен компьютерда модельләштерү алымнары уйлап табу... Болар – яшь галимнәрнең узган елгы фәнни ачышлары. 8 февраль – Россия фәне көне. 2024 ел исә республикада Фән һәм фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде. Яшьләр фәнгә нинди өметләр белән килә? Үзләреннән сорадык.

Нефть табы

Ольга Корнетова – Чистай районының Чуаш Ялтаны авылы кызы. КХТИның нефть һәм химия факультетын тәмамлаган. Идел углеводород чималы фәнни-тикшерү институтында эшли башлавына – ун ел.

– Мәктәптә укыганда нефтьне пыяла пробирка эчендә генә күргән бар иде. Тик үз кулың белән тотып карамыйча, нәрсә икәнен белеп булмый. Беренче тапкыр чын нефтьне шушы институтка эшкә килгәч кенә тотып карадым. Бер тапкыр хәтта ялгыш өстемә дә түктем әле. Өйгә кайткач, көч-хәл белән юып бетердем. Татарстандагы нефть ул каймак кебек куе һәм сыланучан. Татарстанда чыгарыла торган авыр нефтькә кагылышлы диссертация дә яздым, – ди 33 яшьлек фәнни хезмәткәр.

Ольга Корнетова әйтүенчә, фән ул – кызык һәм иҗади эш. Тәҗрибәләр үткәреп, анализлар алып кына калмыйча, нефть, нефть продуктларын, углеводород газларын күкерттән чистарту буенча проектлар да булдыралар.

– Дөнья масштабындагы ачышлар ясамасак та, көн саен эшнең яңа якларын ачып торабыз. Лабораториягә нефть пробалары алып киләләр, без анда күпме күкерт водороды, меркаптан һәм башка компонентлар барлыгын тикшерәбез. Шуннан соң күкерттән чистарту өчен тиешле технология сайлыйбыз, аның схемасын әзерлибез. Бөтен эш шуннан башланып китә, – ди ул.

Бәйге, төрле грантларда катнашу институт өчен алай табышлы түгел икән. «Грант оту күбрәк уку йортларына килешә. Безнең өчен нефть һәм газ эшкәртүче предприятиеләр белән хезмәттәшлек итү кулайрак, чөнки институт үзенең технологияләрен тормышка ашыру белән шөгыльләнә. Финанс ягыннан да бу отышлырак», – ди Ольга. Шуңа күрә мондагы галимнәр 2–3 миллион сумнан башланган кыйммәтлерәк проектларда катнашырга тырыша. Яшь белгеч, хезмәт хакы күп булмаса да, яшәргә җитә, ди.

Яшьләргә – лабораторияләр

Узган ел КФУ доценты Ирек Мөхәммәтдинов яшь галимнәр өчен фән һәм инновацияләр өлкәсендә Россия Президенты премиясенә лаек булган иде. Ул катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен махсус катализатор уйлап тапты.

– Безнең команда РНФ (Россия фәнни фонды) грантын алды, хәзер натрийга нигезләнгән катализаторлар өстендә эшлибез. Алар нефтьне күкерттән арындырырга, нефть сыйфатын яхшыртырга тиеш, – диде Ирек Мөхәммәтдинов яңа казанышлар турында.

Яшь галим белдергәнчә, хәзерге студентларның күбесе фән белән шөгыльләнергә тели. Килешү буенча лабораториягә эшкә урнаша. Шулай ук аспирантурада укуын дәвам иттерүчеләр дә җитәрлек. Дәүләтнең яшь галимнәргә илкүләм проектлар, төрле программалар булдыруын да хуплады ул.

«Беренче тапкыр чын нефтьне эшкә килгәч кенә тотып карадым», – ди Ольга Корнетова.

Сан

Татарстанда барлыгы **4500** яшь галим исәпләнә. Бу – барлык галимнәрнең **60** проценты.

Файда

«Фәндә баеп булмый». Казандагы В.Б. Шнепп исемендәге «НИИтурбокомпрессор» фәнни-тикшеренү институтының гыйльми секретаре, яшь галим Илмир Хәбибуллин әнә шулай ди. Аның фикеренчә, баеп булмаса, халыкка хезмәт итеп була.

Узган ел Илмир Хәбибуллин «Татарстанның иң яхшы галиме» бәйгесендә икенче урын алган, В.Е. Алемасов премиясенә дә лаек булган. Аның фәнни хезмәтләре газ компрессор станцияләрендә җылылык алмашын арттыруга бәйле. Институтта хезмәт юлын инженер-конструктор буларак башлаган егет. Шул ук вакытта газ турбиналы двигательләрне, компрессор станциясе өчен һаваны суыту аппаратын ясауга керешә. Ул җиһаз ел дәвамында ачык һавада эшләгән. Салкында да, эсседә дә сыналган, кыскасы. Хәзер җитештерүдә кулланыла.

Илмир Хәбибуллин фәнни тикшеренүләр институтында яшь галимнәр, тикшеренүчеләрнең советын да булдырган. «НИИтурбокомпрессор» яшьләре белән Фән һәм технологияләр атналыгы үткәрергә һәм бик күп эшләр башкарырга җыена. Илмир – республиканың яшь галимнәр хәрәкәте әгъзасы. Алар анда үз идеяләрен тормышка ашыра.

Тумышы белән Түбән Кама шәһәреннән ул. КАИны тәмамлагач, үзе укыган вузда эшкә калган. Көндез заводта эшләп, кичен студентларга белем бирә. Менә шунда вуз тикшеренүләре белән җитештерү арасында аерма зур булуын аңлый.

– Безнең материал җитештерүчеләргә актуаль түгел иде. Яңа эшләнмәләр турында да белмәдек. Әлбәттә, теория дә, китап уку да кирәк. Әмма заводта эшләүче яшьләргә үз куллары белән эшләгән әйберләр күпкә кызыграк. Предприятиеләр үз казанында гына кайный. Шуңа күрә аспирантларга базар икътисадында ниләр майтарылуын аңлау бик авыр. Кирәк әйберне интернеттан тапсалар да, ахырга кадәр төшенә алмыйлар. Булган теоретик һәм гамәли белемнәрне арттырырга кирәк, – ди яшь галим. – 2022 елдан игълан ителгән Фән һәм технологияләр унъеллыгында менә шуларга игътибар бирелә. Дөрес, вазгыять әкренләп үзгәрә башлады. Вуз, предприятиеләрне реаль икътисад секторына берләштерү сизелә. Югары уку йортларында предприятиеләрнең инженерлык үзәкләре булдырыла башлады. «НИИтурбокомпрессор»да студентлар ярты ставкага эшли. Без аларны фән һәм житештерү белән таныштырабыз. Студентлар диплом язганда, икътисадка нәрсә кирәк икәнлеген белә инде.

Яшьләр фән елында ниләр көтә? Беренче чиратта, хезмәт хакларының артуын. Икенчедән, яшьләрнең предприятие, оешмалар эшчәнлегендә, шулай ук илнең фәнни-технологик үсешендә актив катнашуын. «Фәнне популярлаштыруга өлеш кертеп, планнарын тормышка ашырсыннар, киләчәккә максатларын билгеләсеннәр иде», – ди алар.

Сәрия МИФТАХОВА

НИЛӘР БЕЛӘН ШАККАТЫРАЛАР?

Татарстанның Яшь галимнәр һәм белгечләр хәрәкәте башкарма комитеты рәисе Юлия КАРЕЕВА:

– 2023 ел ачышлары арасында медицина, ветеринария, тарих һәм археология, авыл хуҗалыгы, биология, физика, химия, нефть-газ геологиясе һәм геофизика, энергетика һ.б. өлкәгә караганнары бар. Җитди эшләнмәләргә грантлар бирелде, алар тормышта да кулланылачак. Россия фәнни фондының (РНФ) төп фәнни нәтиҗәләре үзенчәлекле. Былтыр хайваннарда баш мие яман шешен яңача ачыклау, һава шартларына чыдам булган бодай сортларын үстерү өчен компьютерда модельләштерү алымнары, геотермаль электр станцияләре төзү өчен вулканнарны 3D модельләштерү ысулы уйлап табылды. Күп кенә тикшеренүләр заман белән бергә бара. IT технологияләрне куллану гаҗәеп нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге бирә.

Фикер

Алексей КАЛАЧЕВ, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге директоры:

– «Фән һәм университетлар» илкүләм проекты кысасында төп бурыч – яшьләр лабораторияләрен булдыру һәм үстерү. Хәзерге вакытта фәнни үзәктә ун лаборатория эшли инде. Бу сан арта бара. 2022 елда микроэлектроника юнәлеше буенча лаборатория ачылды. Яшьләр Зеленоград предприятиеләре белән актив хезмәттәшлек итә. Болар барысы да технологик бәйсезлек ягыннан да, импортны алыштыру мәсьәләләрен хәл итүдә дә бик кирәк. Моннан тыш, илкүләм проект кысасында республикада Селекция-орлыкчылык үзәге төзеләчәк. Анда бәрәңгенең, бөртекле, кузаклы, ярма һәм җиләк-җимеш культураларының яңа сортларын һәм гибридларын ачыкларга ярдәм итәчәк фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәреләчәк.

Роза ӘХМӘДИЕВА, Татарстан Ректорлар Советы рәисе урынбасары, Казан дәүләт мәдәният институты ректоры:

– Аспирантурада укып, вузга эшкә килгәндә, хезмәт хакым нибары 500 сум иде. Әлеге акча транспортта йөрергә дә җитмәде. Тулай торактан институтка җәяү йөрдем. Хәзер актив студентларга, яшь мөгаллимнәргә грантлар да, ярдәм чаралары да куп. «Вузның иң яхшы мөгаллиме», «Республиканың иң яхшы мөгаллиме» бәйгесе җиңүчеләре саллы премияләр ала.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ШӘҺРИ АЙЛЫ КАРАГАЙ

Карагай исемле зур гына татар авылы Төмән өлкәсенең Вагай районында урнашкан. Нәрсәсе белән данлыклы дисәгез, ул – махсус хәрби операциядәге батырлыклары өчен Россия Герое исеменә лаек булган милләттәшебез Рөстәм Сәйфуллин яшәгән һәм укыган авыл.

Туган якта очрашу.

Геройның батырлыклары турында без язып чыккан идек инде. Шуннан бирле элемтәләрнең өзелгәне юк дип әйтергә дә була. «Бездәге кебек матурлык башка җирдә юктыр ул. Кунакка килегез әле. Бер күреп китәрсез», – дип, кунакка да чакыралар хәтта. Ераграк шул. Төмәннән 400 чакрым – Вагайга, аннан 100 чакрым – Карагайга. «Да, хәлләр шулайрак, агай», – дип башың кашып куярсың. Хәер, дөнья хәлен белеп булмый инде. Кем белә, бәлки, теләкләр чынга да ашып куяр.

Герой исемендәге мәктәп

Гел сөйләшеп торабыз дигәч тә, Рөстәм үзе дә (дөрес, савыгып, хезмәт итә башлаганнан соң, аның вакыты чикләнде кебек), якташлары да юк-барга элемтәгә чыкмый. Гел нинди дә булса яңалык җиткерәләр. Бу юлы Герой исеме бирелгән яңа мәктәпнең төзелеп бетүен һәм 15 мартта ачылачагын хәбәр иттеләр. Бик шатланганнар. Бүген җәмгысы 62 бала укый икән Карагай урта мәктәбендә. Укучыларның яртысы – үзләренеке, яртысы 8 чакрым ераклыктагы Абаул дигән татар авылыннан. Дөрес, анда да белем йорты булган. Ябып киткән. Шуннан соң балаларны автобус белән Карагайга гына йөртергә булганнар. Әлеге дә баягы, татар авылы булгач, татар теленең ничек укытылуы турында беләсе килә бит инде. Бу хакта без элек татар теле укыткан, Рөстәм Сәйфуллинның сыйныф җитәкчесе Галия Илчебакиева белән сөйләштек. Үзе хәзер лаеклы ялда ул. Татар теле укытуның хәзерге торышы белән әллә ни мактана алмады, зарланмады да. «Нишлисең инде, белгечләр юк бит», – дию белән генә чикләнде.

Белгечләр дигәннән, Галия ханым үзе кайчандыр Алабуга педагогия институтын тәмамлаган. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәре алып чыккан. Шушы белгечлеккә хыянәт итмичә, 37 ел буена татар теле һәм әдәбиятыннан белем биргән. Ул вакытларны искә төшергәндә, елап та, көлеп тә ала.

– Без Төмән өлкәсеннән Алабугага максатчан юллама белән өч кыз киттек. Кәеф күтәренке: күңелне, менә укып кайтырбыз да милләтебез өчен көрәшкә күтәрелербез, дигән уйлар били. Тик җиңел генә булмады әле ул. Башта сагынудан интектек. Каникулга чыккач: «Башка бу якларга әйләнеп тә карамыйбыз. Ташлыйбыз укуны», – дип китәбез. Тагын әйләнеп кайтабыз. Тора-бара ияләштек. Шунысы кызык: укуымны тәмамлап, туган якта эшли башлагач, гел Татарстанны сагынып яшәдем. Тик барырга җае да, мөмкинлеге дә юк кебек иде, ерак кебек тоелды. Ирем Хисаметдин белән ике кыз үстердек. Хәзер икесе дә Сургутта яши. Бервакыт шулай кунакка кайттылар да, гаилә альбомнарын актарып утырабыз. Мин укыган еллары турында сөйлим дә сөйлим боларга. Ахыр чиктә түзмәделәр: «Әни, әйдә, сине Казанга алып барып кайтабыз. Бездән бүләк булыр», – диделәр. 2011 ел иде бу. Шуннан соң юл ачылды: ике тапкыр барып кайтырга җөрьәт иттем. Сабакташларым белән гел элемтәдә торам. Күбесе Казанда яши.

Татарстаннан татар теле укытучысы булып белем эстәп кайтучылар без соңгысы булмадыкмы икән? Элек бит Төмән институтында да татар теле буенча белгечләр әзерләүче бүлек бар иде. Ул да бетте, Татарстанга да җибәрми башладылар. Башта мин үзебездән шактый еракта урнашкан бер авылда эшләп алдым. Аннан урын бушады да, туган авылга кайттым. Бу минем хыялым иде. Гөр килеп яшәдек, яратып эшләдек. 25 ел буена олимпиадаларга йөрдек. 1997 елда бер укучым хәтта бөтенроссия олимпиадасында призер булды. Хәзер инде Карагайда махсус белемле татар теле укытучылары юк. Шуңа күрә, зарланырлык булмаса да, белем дәрәҗәсен үзегез чамалыйсыздыр. Татар авылында балалар күптән инде русча сөйләшүгә күчеп бара. Йөрәк әрни. Әмма атнага бер керә торган татар теле дәресе белән дә ерак китеп булмый шул. Саф татар телендә сөйләшә торган өлкән яшьтәгеләр дә китә бара.

Утын Омскидан килә

– Машина белән чыксак, юллар әйбәтме соң? – дип сорау биргән идем, һаман да Себерне күреп кайту идеясен ташлый алмыйча. Монысы да барып чыкмады. Асфальт юл Төмәннән Вагайга кадәр генә икән. Карагайга кадәр вак таш түшәлгән түшәлүен. Әмма анысы да күптән күтәртелгән булып, урыны-урыны белән сафтан чыгып бара, ди.

– Авыллар бездә бөтенләй юлсыз әле, – ди Галия ханым. – Дөрес, бер урамыбызга – Яшьләр урамына вак таш түшәделәр. Анысы да Герой укыган авыл булгач, түрәләргә кайтырга туры килгәнгә түгелме икән дип уйлыйм.

Яшьләр урамы булгач, шундук тагын бер сорау туды:

– Авылыгызда яшьләр шулай күпмени, төпләнеп калалармы?

– Юк инде. Берничә гаилә башка чыгып, йорт төзеп чыккан иде. Калырлар иде дә, эш юк. Болары да вахтага йөреп эшлиләр.

Вахта дигәннәре нефть өлкәсенә бәйле булып чыкты. Димәк, газ мәсьәләсе хәл ителгәндер, дип уйладым үземчә. Юк икән. Бу сорауны биргәч, Галия ханым көлде генә.

– Утын ягабыз без. Җәй буе әзерлибез. Менә Абаул авылы турында әйткән идем бит әле. Аннан соң Омск өлкәсе башлана инде. Анда да зур-зур татар авыллары. Утынны бер машинасын 15 мең сумга Омск өлкәсеннән китереп бирәләр. Белөм инде, хәзер: «Үзегездә урман беткәнмени?» – дип сорау бирәчәксез. Урман күп. Тик аны кисәргә, алып кайтырга кирәк бит. Аңа бик күп акча китә. Ә монда түмәрләп кискәнне кайтарып аударалар. Безгә ярасы гына кала.

Изгеләр авылы

Карагайда «Иртыш» ансамбле эшләп килә. Галия ханым шалтыраткан саен бу хакта әйтмичә калмый. «Төшенкелеккә бирелеп тормыйбыз әле. Рәхәтләнеп җырлыйбыз-биибез. Хәләл җефетем Хисаметдин – тирә-якта бердәнбер гармунчы. Күрше авылларга да йөрибез», – дип әйтеп куя.

Менә шундый вакытларда татар авылларының тарихы турында да гәпләшеп алалар, истәлекләрне җыймаска, балаларга сөйләп калдырырга тырышалар икән. Чыннан да, бай тарихлы авыл булып чыкты Карагай.

Борынгы гарәп китапларында аны «Шәһри айлы Карагай» дип атаганнар. Элек ул шәһәр булган.

> Элек Карагайда йортлар чәчелеп урнашкан. Урамнар соңрак кына барлыкка килгән. Бүген бу авылда 18 урам, 3 тыкрык бар. 352 хуҗалыкта 1023 кеше яши.

Авыл янәшәсендә бик биек, горур карагайлар үсә. Авылның исеме шуңа бәйле, дип фаразлыйлар. Андый агачлар, гомумән, Иртыш буенда бик күп, диләр. Бу якларда үз вакытында Изгеләр яшәгән, дип фаразлана. Алар янәшәдәге Тәнбүрән авылыннан ерак түгел җирләнгәннәр. Чыганаклардан күренгәнчә, Карагай авылы янәшәсендә Солтан Шаехнең башкаласы булган. Бу авыл хакында рәсми төстә XVI гасырга караган документларда языла.

Сүз дә юк, 2022 елдан Герой егете булган Карагай авылы тарихында яңа этап башланды, дип горурланып әйтергә була. Бу авылда Рөстәмнең әтисе Нургали абый яши. Савыкканнан соң үзе укыган Төмән югары хәрби-инженерлык училищесы начальнигы урынбасары булып хезмәт итүче егет әтисе йортына эзен суытмый. Балаларның да иң якын дусты ул, аларны батыр булырга өйрәтә. Арада хәрби училищега китәргә теләк белдерүчеләр дә күп икән.

Бабамнан үрнәк алдым

Шул җәһәттән Рөстәм белән дә сөйләшеп алдык.

– Минем хәрби хезмәткә тартылуыма беренче чиратта, мөгаен, Бөек Ватан сугышы турындагы әдәби әсәрләр тәэсир иткәндер дип уйлыйм, – дип, ерактан башлады ул сүзен. – Бабаларыбыз нинди авыр чорда да сынатмаганнар, үлем белән күзгә-күз очрашып, җиңү яулаганнар. Бары тик Ватанны саклау турында гына уйлаганнар. Әтием ягыннан Минахетдин бабам да 1940 елда хезмәткә алынып, сугыш юлларын үтеп, япон самурайларын тар-мар итеп, туган йортына 1947 елда гына әйләнеп кайткан. Ә тылда калган әбиләребез ничек хезмәт иткәннәр?! Мин 7 нче сыйныфка укырга барган елны гаиләбез Абаул авылына күченде. 12 чакрым ераклыктагы бабаларым яшәгән Карагай мәктәбендә укырга, шунда яшәргә туры килде. Бабамның холкы корырак булса да, ни дәрәҗәдә нык ихтыярлы, гадел булуына соклана идем. Хәзерге буынга әнә шул гаделлек җитми. Хезмәт кешенең тормышын мәгънәле итә. Мин нәкъ менә Карагай авылында шушы сыйфатларны үзләштердем дә инде.



Герой исеме бирелгән яңа мәктәп.

22 ЯШЕНДӘ ГОМЕРЕ ӨЗЕЛГӘН РӘЙХАНӘНЕҢ ТУГАННАРЫ:

«МӘҢГЕ ТӨЗӘЛМӘС ЯРА БУЛДЫ УЛ»

1996 елның 29 гыйнварында Теләче районының Олы Мәтәскә авылында була бу коточкыч хәл. Декрет кәгазьләрен алырга дип юлга чыккан Рәйханә Шәйхиеваның гомере 22 яшендә өзелә. Аны туарга да өлгермәгән нәни кызчыгы белән бер кабергә җирлиләр.

Ике абыйсы, ике апасы өчен күтәрә алмаслык ачы хәсрәт була ул. Ә бит язмыш моңа кадәр дә нык сынаган үзләрен. Әниләре Тәгъзимә апа үлгәндә, Рәйханәгә әле сигез генә ай була. Аннан зурраклары – Равил, Рәис, Рәхилә, Равиләгә кечкенәдән язмыш сынауларын татып үсәргә туры килә.

– Әти без ким-хур булмасын өчен барысын да эшләде. Әнисез дип кимсенмәс өчен, безгә иң матур киемнәр алып бирде, чаңгыбыз да бар иде, велосипедта да йөрдек. Әти оста куллы булды. Нинди эшкә тотынса да, шуны башкарып чыгар иде. Җәен басуда эшләсә, кышын тегермәндә он тартты. Агач эшенә оста иде. Кемгә нәрсә кирәк, шуны ясап бирде. Тәрәзә йөзлеге дисеңме, рамнарымы, хәтта өйләр дә салышты, – дип искә ала Равилә апа. – Шулкадәр яхшы күңелле кеше иде ул. Тик яман чир дигәннәре иртәрәк алып китте. Пенсиягә чыгасы елы иде. Яшәгән булса, кадерләп кенә торыр идек үзен. Безнең тормышларыбызны күреп сөенер иде. Үзебез әти-әни булсак та, оныклар сөйсәк тә, әнине дә, әтине дә бик сагынабыз.

Әтисенең бакыйлыкка күчүен Рәйханә дә бик авыр кичерә. Сагына ул туган йортын. Казанга укырга кергәч тә, атна саен авылына кайтып йөри. Әниләре үлгәч, биш баланы үз канаты астына алган Халисә апасын да ташламый.

Рәйханә Казан дәүләт университетының журналистика факультетында белем ала. Төркемдәшләре аның бик акыллы, кешелекле булуын искә алалар. Укып бетергәч, районга кайтып китә ул. Шунда эшли. Авылдашы Рафиска кияүгә чыга. Үзе туып-үскән йорт бушап калса да, Рәйханә нигезне бетерми.

– Гаиләбезгә кайгы килгән көнне сеңлем, авылдашыбызның машинасына утырып, район үзәгенә барырга дип юлга чыга. Ерак китә алмыйлар, каршыларына килгән машинага бәреләләр. Алда утырган Рәйханә шундук җан бирә. Кызчыгы карынында калды. Аны алмадылар. Икесен бергә җирләдек.

Аяз көнне яшен сугу белән бер була бу фаҗига. Туганнар нишләргә дә белми. Бу хәсрәтне бик авыр кичерәләр.

– Рәйханә үлгәннән бирле, аның фотоларын бер дә карый алмадык. Йөрәккә авыр иде. Ятимлекне авыр кичергән балалар бит без. Әни дип әйтергә тилмереп яшәдек. Әтине дә кадерли алмадык. Ә бит тормышның иң матур чагы иде. Беребез өчен беребез утка-суга керергә әзер идек. Тормышлар җайланып беткәндә генә, сеңлебезне югалту әле дә йөрәкне тырнап тора. Мәңге төзәлмәс яра булды ул, – ди Равилә апа. – Быел Рәйханәне искә алу кичәсе була дигәч, күз алдыннан кечкенә сеңлебезнең бар тормышы үтте. Ул көндәлек алып барды. Шуны яңадан кат-кат укыдык. Рәхәт булып китте. Бергә укыган төркемдәшләре, дуслары кайткан иде. Бик матур итеп искә алдык. Сеңлебезнең рухы шатлангандыр, дибез. Еллар узса да, күңелдәге яра бер дә төзәлми. Янәшәбездә булса, нинди бәхетле булыр идек. Тик язмышларны үзгәртеп булмый.

КҮҢЕЛ КҮЗЕ АЛДАМЫЙ

Апас районының Шыгай авылында гомер итүче Зәйтүнә Яруллинаның биш ел инде күзләре күрми. Элеккеге кебек тәмле ризыклар пешереп балаларын сөендерә алмаса да, ягымлы сүзләре, яхшы киңәшләре белән аларның күңелен күрә. Яшьлеге авыр булса да, картлыгы кадер-хөрмәттә аның.

– Кече Күккүзнеке мин. Шыгайга кияүгә чыктым. Ачлыгын да, ялангачлыгын да күрдек. Урман да кистек, гектар-гектар чөгендерен дә үстердек. Бер дә зарланмадык. Яшьлек белән сизелмәде дә ул авырлыклар, – дип искә ала әби. –12 яшемнән эшләдем. Гаиләдә беренче бала булгач, бар эш миңа эләкте. Хәзерге балалар кебек иркәләнеп утыра алмадык. Уенның ни икәнен белми үстек. Үзебез дә сабый гына идек бит инде. Ничек көчебез җиткән диген?! Ул урман кисүләр бер дә онытылмый. Дүрт кызны 18 йортлы авыл янындагы урманга җибәрделәр. Икебез качып кайтып китте. Калганнарыбыз ирләр белән беррәттән 10 көн урман кистек.

Сугыш тәмамлангач, Зәйтүнә әби фермага эшкә килә.

– Сарыклар карадым. Эшемне яратып башкардым. Алдынгы булдым. Бервакыт, бүләк итеп, дүрт сарык белән бер бозау да биргәннәр иде әле. Тормыш башларга ярап торды ул, – ди әбекәй. – Ирем белән ике бала үстердек. Аның үлгәненә 33 ел инде. Шөкер, бүген улым белән кызым игелек күрсәтә. Күзләрем күрми дип утырмыйм. Үземә кирәкне эзләп табарга өйрәндем.

Кызы Фәнзилә апа да әниле булуына сөенеп яши. Гомере буе без дип яшәде, ди ул әнисен.

– Без йокыдан торганчы, мичкә ягып, кайнар кабартмаларын, коймак, кыстыбыйларын пешереп куяр иде. Бик сабыр ул, уңган. Беркайчан да эчтәгесен тышка чыгармый. Безне дә шуңа өйрәтте. Ничә яшьтә булсаң да, әни кирәк. Энем Рәхимулла белән безгә терәк әле әниебез. Аның янында бик рәхәт. Үзен йортта алганына сөенәбез. Аның күңел күзе яшәтә безне.

Зәйтүнә әби сукыр калуынаияләшкән инде. Кайчандыр дөньяның бар матурлыгын күреп яшәгән кешегә кинәт кенә караңгылыкка чуму җиңел булмаса да, ул сынмый.

– Күзләрем күрмәсә дә, мин үземә булган җылыны тоям. Балаларым, якыннарымның яратуын сизеп яшим. Иң мөһиме – күңел күзе. Ә алар бер дә алдамый, – ди ул. – Тормышта төрле хәлләр була. Авырлыкны да күтәрә алырга кирәк. Берәүнең дә биштәре буш булмый. Шуңа күрә көчле булырга, авырлыкны җиңә белергә, сабыр булырга кирәк. Түзем кеше генә бәхетле була.

Рәхмәт ишетү рәхәт

Узган атнаның җомга санында Азнакай районының Актүбә бистәсендә яшәүче 46 яшьлек Марсель Ханнановка ярдәм кирәклеге хакында язган идек. 16 ел шикәр чиреннән интеккән ир инде хәзер йөри алмас хәлгә килгән. Аны 67 яшьлек әнисе Рәйсә апа тәрбияли.

Язма басылып чыгуга, бу гаиләгә ярдәм итәргә теләк белдерүчеләр табылды. Киңәш бирүчеләр дә, акча салучылар да булды. Берничә көннән Рәйсә апа шалтыратты. Кешеләрнең ярдәмен күреп, күңеле тулган аның. Кешедән акча сорамас өчен, таксига эшкә кергән ханым үзләренә булышкан кешеләргә чиксез рәхмәтле.

– Сез язып чыгуга, ярдәм итә башладылар. Һәркем кулыннан килгәнчә тырыша инде. Розалия исемле ханым 20 мең сум салган. Моның кадәр ярдәм күргәнем юк иде. Ул акчаларны тотарга да куркып торам. Улыма дип хәләл акчаларын җибәргән һәркемгә, безне эзләп табып, газетага язган журналист Гөлгенә Шиһаповага чиксез рәхмәтебезне җиткерәм. Берәүгә дә безнең хәлдә калырга язмасын, – диде Рәйсә апа.

Без исә, үз чиратыбызда нинди хәл булса да, таянырлык дусларыбызга рәхмәт әйтәбез. Бергәләп, кешеләрне сөендерүне дәвам иттерсәк иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

«КЕШЕНЕҢ ҮЗЕНӘ КУЙГАН БӘЯСЕ БАР. ШУЛ БӘЯДӘН УЛ БЕРКАЙЧАН ДА ТӨШМӘЯЧӘК»

Чәчрәп чыкмый, ә инде сәхнәдә күренсә, энергетикасы белән залны биләп ала. «Рәшә» спектаклендәге Рәшидә аның кемлеген, нинди көчкә ия булуын тагын бер кат раслады. Сүзебез – Татарстанның атказанган артисты Гүзәл ШАКИРОВА турында. Аның белән язмышка аваздаш роль, театр һәм кино дөньясы, проблемалары хакында сөйләштек.

:: Режиссерларның, ничек кенә объектив булырга тырышсалар да, яраткан актрисалары була. Сез – кемнең сөекемле сөяге?

– Миңа калса, режиссер – беренче чиратта психолог. Ул артистның мөмкинлекләрен алдан күрә һәм яраткан-яратмаганга булми. Син, бәлки, бу роль миңа туры килми, дип уйлыйсыңдыр, ә ул булдыра алуыңа ышана. Миңа төрле режиссерлар белән, төрле жанрларда эшләү кызыклы. Артист эшли-эшли генә ачыла. Миңа әле эшлисе дә эшлисе. Биюче дә бит бии-бии остара.

:: Әмирхан Еники әсәре буенча куелган «Рәшә» спектаклендәге Рәшидә роле сезнең өчен нинди мәгънәгә ия?

– Мин аны Аллаһы Тәгаләнең бүләге дип кабул иттем. Моңа кадәр андый рольне уйнаганым юк иде әле. Режиссер Айдар Җаббаров белән дә эшләп карыйсым килә иде һәм нәкъ менә шул чорны, сугыш вакытларын үзем аша кичереп, булган хәлне чагылдыру хыялым да бар иде. Менә шушы ике теләгем бергә кушылып, миңа «Рәшә» булып килеп иреште. Мин аны көттем һәм шундый роль киләчәген сизә идем.

:: Миңа калса, ул сезнең язмышыгызга да аваздаш кебек.

– Язмышлар төрле булса да, Рәшидәнең табигате миңа якын. Рәшидә дә нечкә күңелле, эшен, кешене ярата икән, ул аны чын йөрәктән, ихлас ярата. Мәкер, файда эзләү аңа чит. Тормышта авырлыклар булса да, ул аны күрсәтми, зарланмый. Шуңа ул миңа бик якын һәм кадерле.

Бу роль җиңел бирелмәде. «Рәшә» спектакле сынаулар үтә-үтә туды. Гадәттә бит айлар буе барган репетицияләрдә ролеңне үстерәсең, шомартасың, тудырасың. Ә «Рәшә»не без берничә ай әзерләдек тә бер елга туктaлдык. Шундый зур тәнәфестән соң кабат эшкә тотынып, бер ай эчендә җыеп бетердек. Бу инде – көне-төне сәхнәдә яшәү дигән сүз. Дөрес, театрда андый хәлләр булгалый, әмма бик сирәк. Репетицияләр аз булгач, стресс та кичергәнмен булып чыкты. Чөнки йөрәк аша үткәрмәсәң, бу рольне тамашачыга җиткереп булмас иде. Репетицияләргә, никадәр генә авыр булмасын, ашкынып бардым. Андый чакта аяк астындагы җирне дә сизмисең икән ул. Вакыт дигәнең дә әһәмиятен югалта, ашамый-эчми эшләгәч, ябыкканыңны да күрмисең. Әмма шул вакытта хезмәттәшләрем, кызым таяныч булды. Коллегаларым, син болай эшләсәң, бетәсең дип, эчәргә, ашарга алып киләләр иде. Кызым исә, хәлгә кереп, мине бөтенләй тынычлыкта калдырды. Ул – дүрт айлык вакытыннан бирле сәхнәдә үскән бала һәм минем эшемнең никадәр авыр булганын аңлый. Ялгыш та каприз күрсәтмәде, киресенчә, олыларча, син булдырасың аны, дип тынычландыра иде. Шулай да премьерадан соң бер ай авырдым. Температура төшмичә йөдәткәч, табиблар: «Син бик каты стресс кичердеңме әллә?» – дип сорадылар. «Әйе, эшемдә», – дидем. «Тынычлансаң, бу халәт үтә», – диделәр. Ул шулай булды да. Инде нәтиҗә ясап әйтсәк, «Рәшә» авырлык белән чыкты һәм иң кадерле спектакльгә әйләнде. Мин аны көтеп алам, уйнамый торган араларда сагынам.

:: Әмирхан Еники әсәрләрендә хатын-кыз һәрвакыт вакыйгалардан өстен кала. «Рәшә»дә, мәсәлән, героиня Зөфәрнең тәкъдимен кире кагып, Минзәләгә актриса булып китә. Ә спектакльдә үзен үзе харап итә. Айдар Җаббаровның бу алымын ничек кабул иттегез?

– Башта Айдар Җаббаров белән эшләү үзенчәлекләрен әйтеп үтим әле. Ул бөтен артистларны да тигез күрә һәм игътибарын да тигез бүлә. Һәрбер артистка хөрмәт белән карый һәм ирек бирә. Әгәр аныңча килеп чыкмаса, изми, «Әгәр сиңа шулай җайлырак икән, синеңчә калдырабыз», – ди. Киеренкелекне уен-көлке белән тигезли белә. Репетициягә вакыт аз бирелде, шуңа күрә аның белән эшләү җитми калды. Шул сыйфатлары, тулы ирек бирүе һәм ышанычы өчен рәхмәт аңа. Ә Рәшидә образына килгәндә, режиссер үзенең бу рольне ничек күзаллавы турында әйткәч, мин, әлбәттә, килешмәдем! Ул чакта мин аңа Гүзәл Шакирова булып җавап бирдем, героиняма андый язмыш теләмәдем. Ә инде тора-бара режиссерның хаклы булуына инандым.

> Ул картинаны тулаем күрә, ә мин үз ролем аша гына фаразлыйм һәм хатын-кызны түбәнсетүне, әлбәттә инде, теләмим. Айдар, Рәшидәнең язмышын үзгәртеп, тамашачыга уйланырга җирлек бирде. Кеше кайткач та уйлансын, үз-үзе белән бәхәсләшсен. Театрның бурычы да шул бит инде.

Әмирхан Еникича куйсак, гади булыр иде. Айдар безне тирәнрәк фикерләргә этәрде. Аның исеме дә бит «Рәшә», ягъни алдавыч күренеш, Рәшидәнең үлеме дә, бәлкем, рәшә генәдер... Ул бары юкка чыга. Аның көймәдән юкка чыгуын да бит төрлечә аңлап була һәм һәркем үз каланчасыннан чыгып фикер йөртәчәк. Менә шуларны аңлаткач, мин килештем. Алай катлаулырак һәм кызыграк иде. Марсель абый Сәлимҗанов та режиссерның тамашачыдан алданрак барырга тиешлеген әйтә иде. Бу – тамашачыны өйрәтүе, үз артыннан ияртүе дигән сүз инде.

:: Артистның яраткан роле буламы?

– Егерме ел эшләү дәверендә төрле характердагы рольләрдә уйнарга туры килде. Мин аларның берсен дә аерып әйтә алмыйм. Һәрберсе дә – минем хезмәтем, шул чактагы хис-кичерешләрем бит. Әгәр яшьлектәге берәр ролемне хәзер уйнарга туры килсә, мин инде аны алай башкарып чыга алмас идем. Ул миңа әнә шул самимилеге, ихласлыгы белән кадерле.



«Рәшә»дәге Рәшидә – иң авыр, әмма иң кадерле рольләремнең берсе», – ди Гүзәл Шакирова.

:: Театр гаиләгә ни дәрәҗәдә тәэсир итә? Әгәр үткәннәргә кире кайтырга туры килсә, гаилә хакына театрны ташлый алыр идегезме?
– Минем актриса булу, театрда эшлисе килү кечкенәдән яралган хыял иде ул, ялгыш кереп киткән өлкә түгел. Шуңа күрә мин гаиләне генә сайлыйм дип әйтә алмыйм. Әлбәттә, гаилә беренче урында булды һәм булачак. Гаиләсез кеше – тәрәксез кеше. Шуңа күрә үткәннәргә кайтсам да, барыбер шушы юлны, шушы театрны сайлаган булыр идем.

> Театр да – минем гаиләм! Эшли-эшли шулкадәр бербөтенгә әйләнәсең икән, хәзер инде бусы – гаилә, бусы – эш, дип берничек тә аерып булмый. Кызым да шунда үсте, аның белән бергә мин дә үстем.

:: Кызыгыз актриса булам дисә, риза булачаксызмы?
– Кечкенә чагында аннан: «Артист буласыңмы?» – дип сорасалар, «Юк», – дип җавап бирә иде. Хәзер аңа 15 яшь тулды, бу сорауны бирсәләр, кистереп җавап бирми, уйлана. Кем генә булса да, нинди һөнәр сайласа да, мин аны хуплаячакмын. Чөнки үз эшеңне яратырга кирәк. Теләмичә барган юнәлештә ул бәхетле була алмаячак. Артист булам дисә дә, каршы килмәячәкмен. Гәрчә һөнәрнең авырлыкларыннан саклыйсым килсә дә.

:: Сайларга туры килсә, кайсы: киномы, театрмы?
– Кино ул театрга караганда да авыррак хезмәт таләп итә торган өлкә икән. Театрда тамашачыны тоеп уйнасаң, анда каршыңда нибары бер камера тора. Спектакльнең юлы бар: ул башлана, героиня шул юлны үткәндә үсә, ачыла, кульминациягә җитә, финалга бара. Син шушы юлда үзең дә әчтән үсәсең, өлгереп җитешәсең. Кинода алай түгел. Син режиссерга кирәкле халәтне кисәк күрсәтергә, мең кат кабатларга тиеш икән. Аннан камера арттырып җибәргәнне яратмый, ул аны җәһәт эләктереп ала. Әлбәттә, театр якынрак инде, кино да ошый. Алар бер-берсен тулыландыра, актерны баета, миңа калса. Бу көннәрдә мин Нурихан Фәттах әсәре буенча куелган «Кырык дүртнең май аенда» фильмын (режиссеры – Александр Далматов) көтәм. Анда ролем зур түгел, әмма анда да хатын-кыз язмышы.

:: Соңгы вакытта татар режиссерлары күбрәк классик әсәрләргә алына. Кинода да, театрда да шулай. Сезнеңчә, сәбәбе нәрсәдә?
– Беренчедән, ул әсәрләр – тарихны чагылдырганда төп чыганак. Икенчедән, алар шулкадәр бай, киңкырлы һәм гаҗәеп көчкә ия. Шул ук «Рәшә»не генә алсак та, аны бит үз вакытында басттырырга да рөхсәт итмәгәннәр, ә бүген ул сәхнәгә менде. Көчле әсәр барыбер үз юлын таба һәм вакыты җиткәч, халыкка кайта икән.

:: Без сорап ала алмый торган нәрсәләр дә бар, сорап алып була торганнары да... Бик ошаган роль булса, аны режиссердан сорап ала алыр идегезме?
– Юк, әлбәттә. Ничек сорап аласың инде аны?! Беркайчан да алай эшли алмас идем. Бирелә икән роль, мин аны уйныйм. Юк икән, беркайчан да сорап йөрмим. Бу горурлык та, мин-минлек тә түгел. Бары тик тәрбия. Мине алай тәрбияләмәделәр.

:: Сез – эзләнүчән, үзегезгә бик таләпчән кеше. Театрдан кала тагын ниләр белән шөгыльләнәсез?
– Артист эшләүдән туктарга тиеш түгел. Марсель Сәлимҗанов шулай дип әйтә торган иде. Спортчылар да көн саен күнекмәләр ясый, артист та, үсүдән туктап калмас өчен, көн саен нидер эшли. Физик яктан нык булу өчен, фитнеска йөрим, дикциягә күнекмә булсын өчен, республика сукырлар китапханәсендә диктор булып эшлим. Ә күп вакытымны кызыма багышларга тырышам. Икаү генә булсак та, ул – минем өчен гаилә.

:: Сезнең бүгенге халәтегезгә кайсы монолог туры килә?
– «Кешенең үзенә куйган бәясе бар. Менә шул бәядән ул беркайчан да төшмәячәк». Бу – Рәшидә сүзләре. Ул – минем тормыш девизым да.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

<Дәвамы. Башы 29 гыйнвар, 2 февраль саннарында

«Юлыбыз никадәр авыр икәнен аңлатып бетерергә, язып бетерергә кулымдагы Коръәни Кәримнең буш җирләре җитмәс. Һаман олы туганыбызны калдырып, дөрес эшләдекме дия, йөрәгем сызлый. Дәгъвалы хисләрем заманны каргый, бик мөкатдәс нәрсәләрдән ераклашабыз төсле. Ераклашкан саен, балачактан бирле өебездә күргән инсаннарның кайчак ыгы-зыгы куптаруы, кайчак ипле генә нәсыйхәт тыңлаулары, аш ягында пешкән камыр ризыклары исе, кайнар чәй тәме, түшәк-ятак урыннарының пөхтәлеге – һәрберсенең кадере арта бара. Болар барысы тормышыбызның бик вак нәрсәләре тоелганга күрә, болай язуым ваклык төсле. Туган өемнең ышанычкуәт бирүен ничек аңлатыйм...

Аллаһым, кичер, шул солтан җирләренә барып җитүебезне өмет итеп, кирәгеннән артык сабырсызланам, тәкъдиремнән качып котылырга тырышам, ахры. Сабырсызлыгым өчен бер җәза төсле, юлыбызның очы-кырые күренми. Тизрәк барып урнашсак мәсенә кайтасы иде, уңайсызланды. Карт, аны күргә, чәйчегә эндәште, тагын бер чәй китерергә боерды. Егетләрчә җитезлек белән, мәчеттән сөйләшә-сөйләшә чыгып барган берничә кешегә хәбәр салды:

– Татар мосафирым бар! Мәмләкәттән килгән!

Тегеләре ихластан елмайды, 60 яшьләрдәгесе аерылып калды. Тәрекчә:

– Күзебез айдын олсун! – дип, яннарына килеп утырды. Ягъни «Теләгәнебезгә кавыштык, хәерле булсын!» – аннары татарчага күчте: – Нихәл, Мөнир абый? Әйбәтме?

– Әйбәт кенә. Менә мосафирыбыз бар. Казаннан килгән.

– Шулаймы?! Мин Салих булам.

Мосафир белән кул бирешеп күрештеләр. Бабай таныштырып торды.

– Аты Илнур, әти-әнисе мәмләкәттә икән, саулар. Үзе эшкә килгән.

Ир күзләрен чекерәйтә төшеп карап алды.

– Хәзер килгән-киткән күп инде, Мөнир абый, – дип, бераз саграк кеше икәнен сиздереп куйды.

АЙЗИРӘК ГӘРӘЕВА-АКЧУРА

(ХИКӘЯ)

КУЕНЫҢДА НИ БАР?

иде, тизрәк сине кайтып алу җаен тапсак иде. Аннары, бер заман җитәр, барыбыз бергә кире кайтырбыз, Аллаһы боерса. Ләкин әле һаман Кырым җирен узып китә алганыбыз юк. Алдан хәбәрләшеп куйган берничә адәм бар иде, аларны рас китерә алмадык. Көн саен яңа бер карар кабул итү хәлендә калабыз. Нишлик, башка чарабыз юк. Кире кайтырга уйласак, кайтып җитә алмабыз. Бәлки Кырымда калыргадыр? Әмма бер таяныр кешебезне, ышаныр бер танышыбызны юлда очрата алган юк. Алар да безнең кебек кайсы кайда, типкедә йөри, ахры. Диңгезгә күпкә якынрак булырга тиеш, үзебезне шулай юатабыз...»

Чираттагы сәхифәсен ачканда карт, дулкынланудан, китабын аздан гына идәнгә төшереп җибәрмәде.

«Диңгезгә җиттек! Ерак түгел авыл кешеләре белән кача-поса сөйләшеп, яхшы гына түләү бәрабәренә безгә ярдәм итәрлек берничә адәмле булдык. Кара диңгез буенда көймә ялладык. Кырым җиреннән аерылып, яр буеннан ераклаша баруыбыз авылдагы капка төбен искә төшерде, диңгез дулкыннары Миңзифа апаның яшькә тулган моңсу зәңгәр күзләрен хәтерләтте. Капка төбендә әйтелгән бәхиллек сүзләрен кабатлыйм. Бәхил бул, әти! Бәхил бул, Миңзифа апа! Бәхил булыгыз!

Аллаһыма мең шөкерләр, көймә белән Трабзон шәһәренә исән-имин чыктык. Трабзонда идарәче кебек кешеләргә хәлебезне аңлаттык. 300дән артык чакрым ераклыктагы Самсунг тарафына юлладылар. Анда татар мөһаҗирләр бар, диделәр. Анда 15 көн-фәлән тордык. Тирә-як таулык, чәчәр-урыр өчен басулык җир юк. Җир булмагач, нишлик, китәргә телэдек. Безне Төркиянең үзәгенә таба, Бурса шәһәренә караган Карачабәй җирләренә юлладылар. Самсунгтан 800 чакрым ераклыкта, диделәр. Менә шулай, солтан җиренә баскач та газаплымихнәтле юлыбызның очы-кырые күренми әле. Безнең кебек ары сугылып, бире сугылып йөргән татарларны очраттык. Кайберләре белән бер төркемгә әйләндек. Кемнәр кайда ничек тукталган, сораша-сораша бераз мәгълүмат тупладык. Аннары барлы-юклы мал-мөлкәтне кабат җыйдык һәм Карачабәйгә киттек...»

Мөнир бабай шулай һәр көн китапка кулдан язылганнарны, бәлки инде гомерендә йөзенче мәртәбәдер, укый-укый җомганы көчкә җиткерде.

Көн-төн интернет аша милек сату эшендә кайнаган Илнур өчен җомга бик тиз җитте. Үзе яшәгән кунакханә каршындагы мәчеттә ара-тирә намаз кылды. Җомгага янә шунда, ләкин соңлабрак керде. Ул чыкканда инде карт, нәкъ үткән атнадагы кебек, чәй эчәргә хәзерләнгән, әмма уе гына чәйдә түгел кебек, һәр чыккан кешегә күз салып утыра иде. Көтә, димәк.

Дуртпочмаклы экран дөньясыннан тәүлек дәвамында эш, акча, дус казанган кеше өчен мәчет каршында көпә-көндез чәй эчү, болай гына, планшетсыз утыру акылга сыймаслык бер гамәл тоелды. Бүлмәсеннән ашыгып чыкканга күрә эш коралын алырга онытты. Тизрәк бул-

– Алай дисеңме...

Аннары утырыр-утырмас яңа танышын онытты төсле. Мәхәлләә хәлләренә күчте.

– Кара, Мөнир абый, кичә җеназага бара алдыңмы соң?

– Җеназа бар идеме?

– Тегe, авылда бабалары кибет тоткан Курыкмас Фәйзинең абзыйсы бар иде бит... Исемен оныттым...

– Ә-ә-ә... Фәхриме? Шул вафат иткән?

– Юк. Шуның кызының кияве татар иде, шул мәрхүм, авылга алып кайтканнар. Әтисе Юзгат тарафыннан килгәннәрдән иде. Алар Истанбулда яшәделәр. Белмисеңдер...

– Беләм. Нигә белмәскә?! Ул бит безнең авыл килене Шәмсиянең абыйсы була. Яшьрәк чакта бәйрәмнәрдә күрешә идек. Тукта, ул бит әле яшь! Җитмеш тә юктыр.

– Йөрәктән, ди, теге ковид белән чирләгән булган, ди.

– Алай дисеңме?! Зәхмәт! Күпме кешене харап итте. Мәүли дә шуннан китте, Җәффар да... Мәкамнәре нур булсын, Аллаһ рәхмәт әйләсен.

– Амин. Иртә киттеләр шул. Нык кына йөргән җирдән. Абзый, син элеккеләрне әйбәт хәтерлисең бит.

– Хәтерлим! Вай-вай, әүвәле шундый картлар бар иде! Мәмләкәттән килгәннәр барысы эреләр, гайрәтлеләр! Бишмәт кияләр иде. Бишмәт кигән картлар иде, кайсы берсен сөйлим... Без – бала-чаганы яңгыр килә башласа: «Күкри бабай килә, качыгыз!» – дип куркыталар иде. И-и-и... Шуңа ышанып куркып кача идек... – Салих Мөнир картны бүлдерергә кыймады, тыныч кына чәй эчүен дәвам итте. – И-и-и... Әүвәлге картлар... Йөз чакрым түгел, мең чакрымны җәяү үтәрлек картлар бар иде. Бер картлар бар иде, бер картлар! Вай-вай, акылың хәйран калыр! Авылда берсе атына арбасын җиккән, шуннан өеннән хатынын, баласын алып чыгып утырткан, Казанга кайтып киткән! Сагынуга, җирсүгә түзә алмаган. Карс шәһәреннән, Азәрбайҗан аша ат белән мәмләкәттәге авылына кайтып килгән. Казанда мәдрәсәдә укыган, гыйлемле иде. Вай-вай, аңлата иде кайтуларын, кире килүләрен... «Моннан кире кайтырга җыенганда атыма: «Җәһәтрәк кылан, кире әйләнеп кайтасы да бар!» – дип шаярткан идем, фәрештәләрнең: «Амин!» – дигән чагына туры килдеме, кабат чыгып киттек Казаннан. Кая анда яшәү, инкыйлабчылар басып алган бөтен җирне!» – дия иде... Ә бер заманнар, җир тетрәгәч, Төркиядәге татар авылында өйләргә шактый зыян килде бит. Бер татар картының өе ишелгән икән, дәүләт хезмәткәрләре килгән. «Ничек ярдәм итә алабыз?» – дип сораганнар. Бу: «Ихтыяҗы булганнарга ярдәм итегез. Өйне үз кулларым белән салып керермен», – дип әйтә икән. Ихтыяҗы булганнарга дигән, үзенең бер дә ихтыяҗы юк кебек...

Дәвамы бар >

Беләсең килсә...

1 Психотерапиядә хоардинг төшенчәсе нәрсәне аңлата?
а) Мюнхгаузен синдромы;
б) Ван Гог синдромы;
в) Плюшкин синдромы.

2 Хәзер нинди ел бара?
а) Аждаһа елы;
б) Куян елы;
в) Арыслан елы.

3 «Ялкын» журналы элек мондый исемдә чыкмаган:
а) «Пионер каләме»;
б) «Яшь ленинчы»;
в) «Кечкенә иптәшләр».

4 Bardak сүзе төрекчәдән ничек тәрҗемә ителә?
а) тәртипсезлек;
б) юл бөкесе;
в) стакан.

Җаваплар: 1. в); 2. а); 3. б); 4. в).

Әз-мәз мәзәк

– Миңа кияүгә чыгарга тәкъдим иттеләр.
– Сер булмаса, кем?
– Әти-әнием.

***

– Ябыгырга булдым әле. Фитнеска, бассейнга һәм хорга язылдым.
– Хор ябыктырамыни?
– Миңа, иң мөһиме, ашарга вакыт калмасын.

***

– Ишетергә иң яратмаган сүзне әйт әле.
– Хәерле иртә, коллегалар!

***

Кияүгә чыккач, хатын-кыз үзен карамый башлый. Ә иргә карата игътибары, киресенчә, арта.

***

Әгәр дә кыш көне кулларыгыз ярыла икән, бер кашык мәтрүшкә алыгыз, лимон, шикәр комы. Шулар белән чәй ясап, өйдә генә утырыгыз, беркая чыкмагыз.

***

Минем бер танышым инде 10 ел бер үк чәчтараш кызга йөри. Ә чәчен башка җирдә алдыра.

***

Әгәр хатынның синнән бу турыда сорый икән, димәк, ул бу турыда белә.

***

– Картлыкта да синең белән бергә буласым килә, матурым.
– Картлыкка җиткерменме, белмим, әмма чәчләреңне тиз агарта алам.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: ул, Эльвира, ТТ, Лидия, нон, уй, Мәдинә, Сәйфихан, би, Ак, мисал, солых, Гита, ТТС, абый, КАИ, уру, калфак, уха, ил, ре, Асама, авазы, күк, хур, коры, аваз, ки, аты, Алика, Тура, яла, Агутин, клиент, асаба, Янаев, ук, явым, шуу, Фидан.

Вертикаль: Гата, мисвак, казу, Диләфрүз, аек, ТИ, нахак, куна, ушу, Әлфинә, ахир, сяку, до, агымсу, азан, уф, Явлинский, ара, бая, им, Тямаев, урт, уймак, акыл, Выша, Латыйфи, ау, акт, истихара, хат, авыл, Алсу, ике, ризык, Баулы, ант.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 215

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+